Сабан туе

Безнең бәйрәм

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ
ИННОВАЦИЯЛӘР ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ САКЛАУ РЕСУРС ҮЗӘГЕ»
ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

САБАН ТУЕ – безнең бәйрәм

Методик кулланма

Казан
2021

Сабан туе

Безнең бәйрәм

Сабантуй – чын-мәгънәсендә милли рух җәүһәре, татар халкының үзенчәлекле мәдәниятенең бетмәс-текәнмәс чишмәсе, аның рухи торышы, һәм талантларны ачу өчен бик яхшы мөмкинлек, җитезлектә, тапкырлыкта көч сынашу...

Татарстан Республикасының беренче Президенты
Минтимер ШӘЙМИЕВ

Татар кайда гына яшәмәсен, ул булган җирдә Сабантуй үткәрелә. Бәйрәмнең географиясе Татарстан белән генә чикләнеп калмыйча, күптән инде Мәскәүнең Измайлово паркында, Санкт-Петербург, Киев, Ташкент, Әстерхан, Саратов, Магнитогорск, Новосибирск, Иркутск шәһәрләрендә, Уфада һәм Башкортстанның башка шәһәр-авылларында, Мордовия, Мари-Эл республикаларында, Киров, Пенза, Самара, Ульяновск, Оренбург, Пермь, Төмән, Кемерово һәм татарлар яшәгән башка өлкәләрдә дә уза. Соңгы елларда татар диаспорасы булган Польша, Германия, Балтыйк буе илләрендә, Франция, Бөекбритания, Америка, Кытай, Канада, Австралия кебек илләрдә дә бәйрәм итеҗә.

Заманча Сабантуй – ул традицион мәдәниятне, барыннан да элек җыр-бию, халык уеннары һәм традицион ярышларны берләштерә торган бәйрәм. Гадәттә, төп мәйданда традицион уеннар оештырылса, параллель рәвештә җыр-бию өчен мәйданчыклар эшли, шулай ук сувенирлар, милли декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре сатыла.

Сабантуй – милли халык бәйрәме. Аның этник функциясе Татарстаннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятне тоярга, аның гуманистик кыйммәтен аңларга мөмкинлек бирә. Сабан туе яшен, милләтен, диннәрен аермыйча, бәйрәмдә катнашучыга карата ихтирамлы, толерант мөнәсәбәткә нигезләнгән. Һәм биредә барлык катнашучыларның да хокукы тигез, теләге булган һәр кеше төрле ярышларда катнаша ала.

Сабантуй – мөһим социологик бурычларны үти торган бәйрәм. Анда халыкның барлык катламы – балалар, яшьләр, өлкәннәр катнаша. Һәр төркемнең традицион мәдәният кануннары белән регламентланган функцияләре һәм бурычлары бар. Сабантуйның буыннар бәйләнешен ныгытуда, халыкның традицион мәдәниятен саклауда роле мөһим.

Сабантуй – тормыш өчен әһәмиятле булган яңа мәгълүмат алмашу урыны, ул үзенә күрә иң яхшы эшләнмәләр «ярминкәсе». Музыкантлар һәм башкаручылар арасында ярышлар социумның музыкаль репертуарын яңартуга ярдәм итә.

Сабантуй – ул гаилә формалаштыру өчен җавап бирүче социаль институт та: әзерлек һәм бәйрәм вакытында яшьләр үзләренә пар сайлый.

КЕРЕШ

Әлеге методик кулланманың максаты – Сабан туе бәйрәме, аны үткәрү традицияләре һәм гореф-гадәтләре турында мәгълүмат бирү, татар халкының милли бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә кызыксыну уяту.

Сабан туе бәйрәме – татар халкының иң олы бәйрәмнәренең берсе. Аның тарихи тамырлары гасырларга барып тоташа. Бу бәйрәм игенчелек культурасыннан үсеп, массакүләм бәйрәм атмосферасына әверелде. Элек ул язның беренче айларында үтсә, хәзер җәй аенда уздырыла.

Сабантуй бәйрәменең традицияләре һәм йолалары әле дә сакланып, ел саен бөтен дөньяга сибелгән татарлар тарафыннан зурлап бәйрәм ителә. Сабантуй – тынычлык һәм милләтләр арасында татулыкны саклауга, барлык кешеләрне берләштерүгә юнәлтелгән образлар, йолалар, кыйммәтләр, карашлар, нормалар һәм кагыйдәләр комплексы ул.

Бу методик кулланма Сабантуй бәйрәме йолаларының тулы палитрасын тәкъдим итә. Биредә күренекле галимнәр М.Х. Бакиров һәм Ф.З. Яхинның мәкаләләре, Сабантуй уздыру сценарийлары урын алган; Сабантуйның төп компонентлары барлана, аны тормышка ашыру өчен гомуми тәкъдимнәр бирелә.

Лотфулла Фәттахов. «Сабантуй». 1957 ел.
Татарстан Республикасы
Дәүләт сынлы сәнгать музее

САБАН ТУЕ ЯМЕ

Дөнья йөзендә һәр халык үзенең гореф-гадәтләре, йола-гамәлләре, киеме-бизәкләре һәм милли теле, әдәбияты, сәнгате белән үз дөньясын төзеп яши. Шулардан берсен генә югалтса да, яшәешенә зыян килә дип күзаллаган. Шуңа күрә дә халыклар яшәешләренең бу ягын туктаусыз кайгыртып торырга мәҗбүр.

Без тормышын матур итеп кора белгән ата-бабаларга чиксез рәхмәтләребезне әйтәбез. Чыннан да, бөек тарих калдырган алар безгә.

Халкыбыз борынгы заманнардан бирле милли йола-гадәтләрне өзми дәвам иттереп яшәп, яңа йолаларга да тартылмый калмаган, мондый адымга үтә зур җаваплылык белән барган, аларга тормыш таләбе итеп караган. Театрларның барлыкка килүе, киемдәге кайбер үзгәрешләр – шундыйлардан. Ислам дине һәм аның йола тәртипләренә бәйле дә шулай булган. Аларда татар халкы, болгар-кыпчак дәверләрендә үк, кешелек өчен әһәмиятле, электән килә торган йола, гореф-гадәтләрнең үзенчәлекле дәвамына да игътибар иткән, шуңа да сөнни мәзһәбенең сәләфийә юлын сайлаган. Сәләфләребез һәр гамәлдә беренче урынга күңел һәм тән сафлыгын куйган, шушыларга бәйләп тормыш-яшәешне матур итеп кору мөмкинлеген күргән. Күңел сафлыгы дигәндә дә уй-хисләрнең бозыклыктан азат булуы таләбе куелган. Тән сафлыгына госел коенуны һәм тәһарәтне саклауны, чисталыкны даими яңартып торуны күздә тотканнар.

Борынгы төрки дәвердә өлкәннәргә хөрмәт белән карау, тормышны алар үрнәгендә дәвам итү, рухларның барлыгына ышану һәм аларга атап ашлар уздыру кебек чараларыбыз булган. Язын һәм көзен гаиләләр, кабилә-кабилә җыелышып, табигать кочагында Җыен бәйрәме уздырганнар. Монда гаиләнең иң өлкән кешесенә елышканнар, ул кулына олы түгәрәк калачны алган, күкрәгенә терәп, аны телем-телем кисеп, гаилә башлыкларына биргән. Алар аны өстенә тоз сибеп, саф чишмә суы белән ашаганнар. Телемне беренче булып ата кеше капкан, аннары олы улына тапшырган, ул, кабып, энесенә, энесе әнисенә, әнисе өлкән кызына, анысы – кече кызга биргән. Угыллар, үз гаиләләрен коргач та, аталары янына җыенга килгәннәр. Әгәр дә кияү кеше әтисез калган икән, ул да аларга кушылган. Әмма үз халкы-кабиләсе олы булса, үзе дә шул кабиләдә өлкән булган атаның олы улы икән, халкы өчен җаваплылык аның өстенә төшкән. Бу гадәтләр ислам диненә күчкәч тә сакланып калган.

Казанда Сабан туе.
1992 елның 21 июне.
Татарстан Республикасы
Милли музее фондларыннан

Халкыбыз гореф-гадәтләрен һәм йолаларын һәммәсен диярлек Ибраһим пәйгамбәргә нисбәт итүчән һәм аңардан башланган дип күзаллаучан. Андый ышану-гамәлләренә бәйле аерым хәбәр-риваятьләр халык арасында электән сөйләнеп килгән. Чиста юынып – тәһарәт алып, госел коенып, әзерләнеп намаз уку, гаеткә һәм ашка җыелудан алып, Сабантуй кебек, гүяки дингә бөтенләй дә катнашы булмаган, керәшеннәрдә дә уздырылучы бәйрәмгә кагылышлы да бу шулай булган. Бөек галимнәребез Риза Фәхретдин баш мөхәррирлегендә, алтын приискалары хуҗасы Дәрдемәнд исеме белән танылган Закир Рәмиев нәширлегендә, 1908-1918 еллар эчендә һәр айда даими икешәр номер чыгарылып килгән «Шура» журналы халыкка кушымта рәвештә җыентык һәм китаплар да тараткан. Шундыйларның берсе 1910 елда дөнья күргән «Шура»ның тел ярышы» җыентыгы[1]. Анда Табул шәһәрендә туып үскән Әхмәт Туктабаевның «Ата-бабадан сөйләнә килгән»[2] дип аталган мәкаләсе басыла. Ул: «Безнең бабаларымызның Ибраһим илче вә юлбашчыдан калмыш туйларымызда һәм чәч туйларымызда безнең арамыздан күп акча туздыручылар күп уладыр»,[3] – дип яза. Ә. Туктабаев нәкъ Р. Фәхретдин рухында фикер йөртә һәм андый бәйрәм-йолаларга зур чыгымнар кертүне тәнкыйть итә. «Бу туйларда, дип аңлата ул, туй иясе ат чаптырадыр, кеше йөгертәдер, кеше узыштырадыр, йомырканы сырга башына бәйләп, суңар ук белән аттырадыр, көрәш кылдырадыр. Бу туйларга ерактан вә якыннан һичбер адәм килми калмыйдыр. Бишәр, алтышар йөгерек атлар җыеладыр. Шулай иттереп, бөтен авылга авырлык төшеп, туй иясе ярлы булып каладыр»[4].

Монда сүзнең никах туйлары хакында түгел, Сабантуйга бәйле алып барылганлыгы аңлашылып тора. «Алар турыдан-туры Сабантуй бәйрәмнәренә бәйле вакыйгалар»[5]. Моны бәхәс итү урынлы булырмы?

Сабантуй бәйрәмнәрен тәртибе белән оештырып, аларда һәммә төрле ярышларда казыйлык итүчеләр электән муллалар һәм намазлы бабайлар була иделәр. Алар һичбер вакыт харамлашуны сөймәделәр. Сабан туенда кече яшьтәге балаларны йөгереш, аркан тартыш, капчык сугыштырыш, көрәш кебек, һәртөрле уеннарга тартып, шуларга дәрт бирүче халыкның күңелен кузгатып, балалардан үсмерләргә, үсмерләрдән егетләргә, егетләрдән ирләргә күчә-күчә барып, бабайлар үзләре дә ак ыштаннарда йөгерешкә чыга торган иделәр. Берсе алгарак йөгерә, икенчесе чатаклап чаба, өченчесе аякларын шактый күтәреп-күтәреп аптырата, яхшы ат, диярсең. Һәркайсы үзенчә кызык ясый. Әмма йөгереш бара. Сабантуйның иң күңелле мизгелләреннән болары да. Мин шуның шаярту, күңел уйнату икәнлеген аңламыйча, егылганын – кызганып, елардай була идем. И, көлә иделәр абый-апалар. Әбиләрнең кашыкка тавык күкәе куеп, бер-берсенә махсус комачау итеп йөгерүләре... Хәтердә: бер әби кашы-

[1] «Шура»ның тел ярышы / Мөрәттибе Ризаэтдин Фәхретдин. – Оренбург: «Вакыт» матбагасында басылды, 1910. – Б.195.
[2] Туктабаев Ә. Ата-бабадан сөйләнә килгән // «Шура»ның тел ярышы... – Б.155-157.
[3] Шунда ук. – Б.156.
[4] Шунда ук.
[5] Яхин Ф.З. Себер татарларына кагылышлы бер язма ядкәр уңаеннан // Гасырлар авазы – Эхо веков. – №4. – 2018. – Б. 164.

гындагы тавык күкәен үзе юри бәреп төшерде дә, аның урынына, каяндыр алып, каз күкәен куйды. Күтәрерлек түгел сыман, әмма көлдереп тә бетергән иде халыкны. Шулай Сабантуй бәйрәме көне буена дәвам итеп, хәтта икенче көнгә кичкә дә калдырыла иде. Анысында инде җыр, бию кебек күңел ачуларга әһәмият бирелә.

1960-1970 елларда халыкта Сабантуйны «Татарстан җыены» дип атау гадәте дә булды. Моның сәбәбе – Сабантуйларның махсус рәвештә Татарстан Автономиясе оешу көннәренә бәйләп уздырылуы. Аннары аның нигә «Сабантуй» дип аталуы белән кызыксынып, «сабан» һәм «туй» сүзләреннән ясалуы хакындагы фаразлар да илдәге вәзгыять өчен ярашлы табылды. Менә шуннан соң «сабан туй» дип, кушма сүзне тезмәдә һәм сызыкча аша язу да гадәткә кертелде. «Сабантуй»ның мәгънәсе русчага да «праздник плуга» дип тәрҗемә ителде һәм шул кузаллауда ул бүген дә яши түгелме?

Риваятенә күрә, Сабантуйның килеп чыгышы Ибраһим пәйгамбәрдән үк килә. Бу яктан «Шура»да мәкаләләре белән катнашып барырга тырышкан Әхмәт Туктабаев бик хаклы. Без, татарлар, күп төрле гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны, әдәп-гамәлләребезне «мөселманга алай килешмәс», «мөселман кешегә үзен ул рәвешле тоту дөрес булыр» дип, шәригать үлчәменә салып фикер белдерүне, кистереп кисәтүне бер дә куймыйбыз. Бүгенге көндә башында кәләпүше, аягында читеге булмаган кешене абыстайларыбыз мөселманга санамый,

Фәйзрахман Әминов.
«Сабантуй». 1950 ел.
Татарстан Республикасы
Дәүләт сынлы сәнгать музее

Абрек Абзгильдин. «Көрәш».
1994 ел. «Сабантуй» циклыннан.
Татарстан Республикасы
Дәүләт сынлы сәнгать музее

яулыксыз хатын-кызны бозык адәм дип күзаллый. Бу бераз читкә калдырып торганнан соң, ашыгып кире кайткан әдәпләребезнең бәлки тәүгесе генәдер? Әмма татар җәмгыятендә ул үз көчен ала бара.

Ибраһим пәйгамбәрнең хатыны Сарадан балалары булмаган. Абыстае моңа бик тә борчыла икән. Яшьләре дә бара, ничек инде, пәйгамбәр кадәр пәйгамбәрнең нәселен кисүче буларак, бәддогага тармыйсың? Ул шуңа да ире Ибраһим пәйгамбәрне башка хатын алырга күндерә. Аңа колы Һаҗәрне никахлаштыра. Ибраһим пәйгамбәрдән Һаҗәр буйга уза. Бу вакыйга Сара абыстайның күңеленә тия. Ул арада, Аллаһының рәхмәте, үзе дә йөкле булгач, Һаҗәргә көн яктысын калдырмый – Ибраһимга аны Хиҗаз иленә сөрергә куша.

Әгәр дә ике хатын алсаң, аларның икесен ике йортта яшәтү тиеш, ди торган иделәр, күңелгә үтәрлек итеп аңлатып, оныкларын тәүфыйкка өйрәткән әбиләребез дә.

Һаҗәр Мәккәгә килеп урнашкан. Анда аның улы туган. Ибраһим пәйгамбәр аларның хәлләрен белешә килеп, улына Исмәгыйль исеме биргән, илне җыеп, туй үткәргән. Менә шулай Сабантуй, ягъни «угыллар бәйрәме» барлыкка килгән. Гарәп телендә «угыллар» «сибйан» булса[6], төрки телләргә ул «сабйан» рәвешендә кулланышка кергән[7]. Телебездә исә, Мөхәммәтҗанны Мокамай, Мөхәммәтне Мамай, Туктамышны Тукай дип, исемнәрне кыскартма тәртиптә атау рәвешенчә берникадәр үзгәртелеп, «сабйан»нан «сабан»га әверелеп беткән. Ә «туй» дигәне «бәйрәм» инде аның, үз сүзебез. Шулай итеп, һәр елны уздырыла торган Сабантуйлар исә угыл балалар туу хөрмәтенә оештырылган, алар кечкенәдән ил-көн, халык өчен җаваплылык хисен тәрбияләү чараларыннан берсе булган. Аннары шунысы да кызыклы, җыеннар уздырганда да халкыбыз шушы ук тәртиптә бәйрәм ясаган.

Бүгенге көндә дә, борынгыларыбыздан килгән гадәтләрне яңартып, хәлле кешеләр Сабантуй оештыруны үз кулларына ала баралар. Ул кайбер очракларда Җыен кебек тә булып китә: читтән кунаклар килә, туган-тумача кайта. Хәзер Сабантуйга атап махсус җыр чыгару да модага кереп китте. Бу һәр татар авылында да диярлек шулай.

Ибраһим пәйгамбәрдән һәм аның улы Исмәгыйль пәйгамбәрдән башланганмы, әллә барлыкка килүенең тарихы тагын да тирәнрәк һәм киңрәкме бу юлда эзләнүләр фәндә дәвам итәр. Фаразый фикерләр дә туа торыр. Әмма шунысы бер хикмәт: Сабантуй ул татар халкының милли бәйрәме, илебездәге мөкатдәс бәйрәм-туйларыбызның берсе. Борынгы бабаларыбыз аны сөя, муллаларыбыз аның үзәгендә иделәр. Безгәме, сәләфийә юлындагыларга, аларның рухларын сөендермәскә, гореф-гадәтләребездә, йола-гамәлләребездә, әдәп һәм әхлагыбызда алар күрсәткәнчә тормышны кормаска, яшәү ямен үстермәскә, бәхетебезне камил итмәскә?

Фәрит ЯХИН,
филология фәннәре докторы, профессор, язучы

---

[6] Баранов Х.К. Арабско-русский словарь: 7-е изд., стереотип. – М. : Рус. яз., 1984. – С. 429.
[7] Сами Ш. Камус төрки. – Дәр-Сәгадәт: «Икъдам» матбагасы, 1318 (1900). – Б. 817.

«Сабантуй» бәйрәме афишасы. 1926 ел.
Татарстан Республикасы
Дәүләт архивы фондларыннан



М. Горький исемендәге үзәк культура
һәм ял паркында Сабан туе.
Казан, 1930 еллар азагы – 1941 еллар.
Н.А. Костин фоторәсеме.
Татарстан Республикасы
Милли музее фондларыннан

М. ГОРЬКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ҮЗӘК КУЛЬТУРА
һӘМ ЯЛ ПАРКЫ
26
ИЮНЬДӘ
САБАН
ТУЕ

М. Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркында Сабан туе афишасы. Казан, 1960 елның 26 июне. Татарстан Республикасы Милли музее фондларыннан

Әлки районының «Кызыл Яр» колхозында һәм «Маслотрест» совхозында Сабан туе. Татарстан Республикасы Милли музее фондларыннан

Сабан туе бәйрәмендә ярыш.
1950 еллар. ТАССР.
Татарстан Республикасы
Милли музее фондларыннан



Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

Чакыру

ХӨРМӘТЛЕ ИПТӘШ!

СЕЗНЕ **Татарстан АССРның 40 еллыгына** багышланган халык бәйрәме **„САБАНТУЙГА“** чакырабыз.

Бәйрәм М. Горький исемендәге культура һәм ял паркында *1960 елның 26 июнендә* була.

12 сәгатьтә башлана.

Юбилей комиссиясе.

ЕЛ 40 ЛЕТ

Пролетарии всех стран, соединяйтесь!

Приглашение

УВАЖАЕМЫЙ ТОВАРИЩ!

Приглашаем ВАС на народный праздник **„САБАНТУЙ“**, посвященный **40-летию ТАССР.**

Праздник состоится в Центральном парке культуры и отдыха им. М. Горького *26 июня 1960 года.*

Начало в 12 часов

Юбилейная комиссия.

ПФ 06001 от 17-VI-60 г.   Татполиграф, 003548

ТАССРның 40 еллыгына багышланган «Сабантуй» бәйрәменә чакыру. 1960 ел. Татарстан Республикасы Милли музее фондларыннан

Сабантуй

Гөлшат Зәйнәшева сүзләре,
Екатерина Шатрова көе

Күңелле Сабантуйлары,
Бүген бәйрәм, зур бәйрәм.
Матур җырлар җырлый-җырлый,
Уйныйбыз әйлән-бәйлән.

Без җырлыйбыз Сабантуйда
Иң матур җырлап сайлап.
Безнең җырга зәңгәр күктән
Кошлар кушыла сайрап.

Күбәләкләр безнең белән
Уйныйлар әйлән-бәйлән.
Сабантуй күбәләкләр һәм
Кошлар өчен дә бәйрәм!

Әти-әниләребезгә
Җыйдык чәчәк бәйләме.
Матур булсын, ямьле булсын
Сабан туе бәйрәме!

Абрек Абзгильдин.
«Чиләкләр белән йөгерү». 1979 ел.
«Сабантуй» циклыннан.
Татарстан Республикасы
Дәүләт сынлы сәнгать музее

Рәшит Заһидуллин. «Тиздән Сабантуй» («Кырлай турында истәлекләр» сериясеннән. Фрагмент). 1987 ел. Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ САБАНТУЙ БӘЙРӘМЕ

Революциягә кадәр Россиядә яшәүче һәр халыкта өч төрле календарь кулланышта булган: беренчесе – рәсми-гражданлык календаре, икенчесе – дини календарь һәм өченчесе – халык календаре. Бу календарьләр күпчелек очракта үзара тәңгәл килмәгән. Пасха яки раштуа, ураза яки корбан бәйрәмнәре; рәсми календарь буенча билгеләп үтелә торган даталар, мәсәлән, Яңа елны каршылау, май бәйрәмен үткәрү; шулай ук халык календаре буенча килә торган йола-бәйрәмнәр – өчесе өч характерда булган һәм төрле вакытларда уздырылган.

Татар халык календаре, башка халыклардагы кебек үк, ел фасылларына һәм авыл хуҗалыгы эшләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Икенче төрле әйткәндә, халык календарендәге төрле даталар, йола-бәйрәмнәр крестьяннарның, ягъни авыл эшчәннәренең ел да бер тәртиптә кабатлана торган хезмәтенә, теге яки бу аграр эшнең кайчан-ничек каршылануына һәм башкарылуына нигезләнеп формалашкан.

Татарлар яшәгән төбәкләрдә элек-электән үткәрелеп килгән Сабантуй да елның билгеле бер чоры һәм игенчелек эшчәнлеге, язгы кыр эшләре белән бәйләнешле милли йола-бәйрәм булып исәпләнә. Бу бәйрәм – «һабантуй» – шулай ук башкортларда бар, ләкин ул тарихчы һәм этнограф К. А. Руденко язганча, аларда чагыштырмача соңрак, игенчелеккә, җир эшкәртүгә бәйле рәвештә формалашкан. Язгы кыр эшләренә бәйле Сабантуйга охшаш йола-бәйрәм чувашларда «ака-туй», мариларда «ага-пайрам» дип йөртелә. Һәм алар икесе дә, башлыча, басуга чыгып күмәк рәвештә игеннәр уңуын теләп гыйбадәт кылу һәм соңыннан җыйнаулашып сыйлану рәвешендә үтүе белән Сабантуйдан аерылганнар.

Безнең фәнни эзләнүләргә караганда, Сабантуй йола-бәйрәмен Урта Идел буена төньяк Кавказ далаларыннан халкыбызның бер этник катламын тәшкил итүче болгарлар алып килгән. Кавказда яшәүче аерым халыкларда зурлап үткәрелә торган һәм ат чабыштыруларын, төрле бәйгеләрне эченә алган «Беренче буразна» бәйрәме булуы мәгълүм. Язгы чәчүгә чыгуга бәйләнешле бу бәйрәмне җирле халыклар «сабанга чыгу», «басу туе» кебек төрле исемнәр белән атап йөрткәннәр[1]. Элек татарларның Сабан туе хәзергечә июнь башында түгел, ә исеме җисеменә туры килгәнчә, «сабан» аенда, ягъни хәзерге май аенда үткәрелеп килгән[2] һәм

---

[1]Чурсин Г.Ф. Праздник «выхода плуга» у горских народов Дагестана // Известия Кавказского историко-археологического музея. – Тифлис, 1927. – С. 87-89; Булатова А.Г. Идеологические представления аварцев, нашедших отражение в празднике первой борозды // Мифология народов Дагестана. – Махачкала, 1984. – С. 82-89.

[2] Урманче Бакый. Сабантуй йолалары // Социалистик Татарстан. – Казан, 1989. – 2 июнь; Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – Б. 12-14.

әлеге календарь бәйрәменең соңгы көне кайбер якларда басуда беренче буразна яру йоласы белән тәмамлана торган булган[3].

Сабан туе вакытында уздырыла торган аерым ярышларның башы исә (мәсәлән, ат чабыштыру, уктан ату, көрәшеп көч сынашу), һичшиксез, һун/гун бабаларыбызның җәйләүгә чыгар алдыннан ел да уздырган борынгы йола-бәйрәменә барып тоташа. Белүебезчә, борынгы гун һәм төрки бабаларыбыз көнкүрешендә ат искиткеч зур роль уйнаган, ат культы көчле булган. Рим тарихчысы Аммиан Марцеллин, мәсәлән, Европа гуннары турында менә нинди сүзләр язып калдырган: «Они коренастые, приросшие к коням. Они настолько сроднились с лошадью, уходу за которой уделяют большое внимание, что считают позором ходить пешком. Они воюют только на конях»[4].

Бер очтан XI-XII йөзләр арасында яшәгән фарсы-таҗик шагыйре Гомәр Хәйямнең кызыклы фикерен дә китерик: «В прошлые времена никакой народ не знал коней – их достоинств и пороков – лучше персов, потому что тогда они владели миром... Сегодня никакой народ не знает этого лучше тюрков, потому что они день и ночь занимаются конем и потому что они владеют миром»[5].

Татарлар да элек-электән ат токкан, ат белән җир сөргән, йөк ташыган, атны көнкүрештә иң якын юлдашы иткән. Менә шуңа күрә дә ат чабышының Сабан туе тамашаларының энҗе кашы кебек кабул ителүе һәм «Атлар килә!» дип сөрән кебек яңгыраган сүзләрнең һәр татар җанлы кешенең йөрәген җилкендерүе бер дә гаҗәп түгел.

Этнографлар һәм фольклорчылар төрле төбәкләрдә яшәгән халыктан Сабантуй йола-бәйрәменең, гомумиләштереп әйткәндә, төп ике төрле вариантын язып алган: озаккарак сузыла торган киңәйтелгән вариантын һәм җыйнак яки кыскарак вариантын. Озын яки тулы вариант әлеге бәйрәм белән турыдан-туры бәйләнештә булмаган йолаларны үз эченә ала һәм асылда бәйрәмгә әзерлек этабы буларак, дөресрәге бәйрәмнең кереш-башлангыч өлеше буларак характерлана. Аны авыл буенча йөреп халыктан ярма, май, сөт кебек ризыклар җыю һәм яланга чыгып, яисә су, чишмә буена урнашып, зур казанда «карга боткасы» һәм «зәрә боткасы» пешертеп ашау йоласы белән бала-чага башлап җибәргән. Бу авылда хуҗалык елының уңышлы килүен теләп пешерелгән корбан ашы рәвешендә күзалланган.

Аннары, ягына карап, әлеге йолага бу юлы инде атларга атланган яшүсмер ир-балалар тарафыннан өй борынча йомыркалар җыю йоласы килеп ялганган. Бу йола сөрән дип аталган, чөнки яз җитү хөрмәтенә яшьләр көр тавыш белән аваз салганнар, ягъни сөрән әйткәннәр. Янә тагын бер кызыклы момент. Белүебезчә, йомырка – үрчем һәм ишәю билгесе, йомырка җыючы сөрәнчеләр дә – үрчем-уңдырышлылыкка ишарә итүче ир җенесле үсмерләр, «орлыкландыручы» зат вәкилләре. Сабантуй йола-бәйрәменә әзерлек һәм кереш хезмәтен үтә-

[3] Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 48.
[4] Марцеллин Аммиан. История. – Киев, 1907. – Вып. 2. – С. 131.
[5] Чурсин Г.Ф. Праздник «выхода плуга» у горских народов Дагестана // Известия Кавказского историко-археологического музея. – Тифлис, 1927. – С. 87-89.

гән һәм дә дулкын кебек бер-берсен куәтләп килгән әлеге йолаларга халык үрчем вә уңдырышлылык мәгънәсен салган, димәк, «алу өчен бирергә дә кирәк» дигән ышанудан чыгып, корбан ризыкларының муллыкка ирештерәчәгенә өмет баглаган.

Сабантуй бәйрәменең соңрак чорда формалашкан җыйнак вариантына исә, әле генә сөйләгән йолалар керми. Бу камилләшкән, «утырып җиткән» вариант турыдан-туры бәйрәмгә бүләкләр җыюдан башланып китә. Әмма аның кереш йолаларның дәвамы, соңгы буыны булганлыгын кайбер якларда, мәсәлән, Пермь ягы татарларында һәм Мамадыш ягында Сабантуйга бүләк җыюның «сөрән йоласы» дип, ә бүләк җыйганда башкарылган махсус җырларның «сөрән җырлары» дип йөртелүе әйтеп тора. Сүз уңаеннан шундый җырлардан мисал да китерик:

Ошбу ла йортның баскычлары –
Барысы да бадьян агачы,
Ошбу ла йортның хуҗалары –
Барысы да былбыл баласы.

Безләр килдек, ай, сезләргә,
Тастымаллар бирдегез безләргә,
Тастымаллар бирдегез, ай, безләргә
Алла исәнлек бирсен сезләргә.

Бүләк җыю бик күңелле һәм тантаналы итеп башкарыла, җыр-музыка һәм уен-көлке белән аралашып бара. Минзәлә һәм Лениногорск районнарында, колхоз-совхозлар исән чакта, бу гамәлгә дистәләгән иң яхшы атлар җәлеп ителә торган булган. Авылдашлары биргән сөлге, яулык, җәймә, тукыма кебек бүләкләрне җайдаклар, очын-очка төйнәп, атларның йөгәненә бәйләгәннәр һәм ияргә элгәннәр. Казан ягында һәм күпчелек авылларда бүләкләрне иң абруйлы аксакаллар катнашында колгага бәйләп җыю гадәткә кергән. Мондый вакытта өй хуҗалары, капка төбенә чыгып, алдан әзерләгән бүләкләре белән бүләк җыючыларны еш кына үзләре каршы ала.

Менә шуннан соң инде Сабантуй бәйрәменең үзенә чират җитә. Аның иң үзәк һәм иң кызыклы өлеше, әлбәттә, мәйдан. Сабантуй бәйрәме асылда нәкъ менә мәйданда һәм төрле ярыш бәйгеләр оештырыла торган урында халыкның язгы сабанга һәм сабан ашлыгы чәчүгә нинди әзерлек белән килүен сынау һәм күрсәтү, тамаша кылу бәйрәме буларак дөньяга килгән дә. Чөнки Сабантуй мәйданында бил алышып, көрәштә физик көчләрен, тазалыкларын тамаша иткәннәр, төрле ярышларда үзләренең куәтен һәм осталыкларын күрсәткәннәр. Кыскасы, үзара көч сынашу-ярышу, куәт һәм сәләтеңне алышта, бөтен халык алдында исбатлап күрсәтү – әлеге бәйрәмнең асыл сыйфатларын тәшкил иткән.

Шунысы характерлы: Сабантуй бәйрәме кайсыдыр яклары һәм иң тирәндә яткан генетик тамырлары белән «җыен» дип йөртелүче (русча «сходка») халык бәйрәме белән авазбаш. Кабилә-ыруг кардәшлегенә нигезләнгән бу бәйрәмне күчмә тормыш белән яшәгән

«Сабантуй» сериясеннән.
1970 нче еллар.
В. Богданов фоторәсеме.
Татарстан Республикасы
Дәүләт сынлы сәнгать музее.
https://m.fotostrana.ru/public/
post/235888/1440908079/

бабаларыбыз җәйләүгә чыгар алдыннан уздыра торган булганнар һәм ул төрле уен-ярышлар белән бергә бәйләп уздырылган. Әмма бабаларыбыз утрак тормышка күчеп, игенчелек белән шөгыльләнә башлаганнан соң да бу бәйрәм юкка чыкмаган, ә яңа шартларга ярашып, печәнгә төшәр алдыннан үткәрелә башлаган. Ул бер община, ягъни бер җыен валиятенә берләшкән төбәктәш авылларның берсендә – үзәк авылда үткән һәм җыен да шул авылның исеме белән аталган. Совет власте елларында исә җыен белән Сабантуй йола-бәйрәмнәре үзара берләшеп киткән һәм Сабантуй, җыен кебек үк, колхоз үзәге урнашкан авылда гына үткәрелүгә күчкән. Әмма революциягә кадәр Сабантуй, җыеннан аермалы буларак, һәр авылда уздырылган. Иң кызыгы һәм иң демократик ягы шунда: мәчет һәм мәдрәсәләрне халкыбыз тоташ үз исәбенә тоткан кебек, Сабантуй бәйрәмен дә үз-үзенә хезмәт күрсәтү рәвешендә, димәк, шулай ук үз исәбенә һәм үз теләге белән оештырган.

Шәһәр җирендә, аерым алганда, Казанда, Уфада, Оренбургта авылдан чыккан татарлар шактый күп яшәгәнлектән Сабантуй бәйрәме акрынлап авылдан шәһәргә дә күчкән. Казанда XIX йөзнең беренче яртысында әлеге бәйрәмнең ничек узганлыгы тасвирлаган истәлекләр белән без Карл Фукс һәм немец сәяхәтчесе Александр Гумбольдт язмалары аша таныша алабыз. 1829 елда, мәсәлән, Сабантуй Татар бистәсендә, 1834 елда Казан ипподромында, ә аннары Пороховой (Дары заводы) бистәсендә уздырыла. Әлеге милли гамәлне оештыруга татар байлары һәм сәүдәгәрләре шактый зур өлеш кертә. 1922 елда Казанда узган Сабантуй исә «Яз бәйрәме» дигән исем астында русларның «Троица» бәйрәме белән берләштерелә. 1940 елда Татарстан Республикасының 20 еллык юбилее уңаеннан Сабантуй бәйрәме Казанда аеруча зурлап үткәрелә. Әлеге милли бәйрәмнең башкалабызда хәтта Бөек Ватан сугышы чорында – 1942 һәм 1944 елларда Бөтенсоюз физкультурниклар көнендә дә уздырылганлыгы мәгълүм. Ә сугыштан соң инде Сабантуй кебек зур милли бәйрәмнең тулы канлы булып кабат әйләнеп кайтуы һәм ел да уздырыла башлавы бик табигый. Нәкъ менә татар халкын берләштерүдә, башка халыкларга танытуда зур роль уйнаганга күрә дә, әлеге бәйрәм элек булмаган төбәкләрдә, мәсәлән, Себер татарларында да уза башлады.

Сабантуй мәйданда уздырыла торган ярыш-бәйге һәм уен төрләренә килгәндә, аларның төп өлеше традицион характерда, милли көрәш, ат чабыштыру, йөгереш, гармунда, скрипка һәм курайда уйнау, шулай ук җыр һәм бию һәр бәйрәмнең элек-электән аерылгысыз юлдашы һәм даими атрибутлары булган. Тора-бара, XIX йөзнең беренче яртысыннан ук инде, бәйрәм репертуарында тамашага корылган төрле уен-бәйгеләр өстәлгән: күз бәйләнгән килеш чүлмәк вату, очына әтәч бәйләнгән шома баганага менү, капчык киеп йөгерү, кашыкка йомырка куеп һәм көянтәгә эленгән сулы чиләкләр күтәреп узышу, бүрәнәгә атланып салам тутырылган капчыклар белән сугышу, аркан тартышу, тирбәлеп торган киртәдә йөрү, кул көрәштерү кебек гамәлләр – әнә шундыйлардан. Һәм үзара тигезлеккә, дустанә мөнәсәбәткә корылган тагын бер җитди момент: бу гамәлләргә теләсә кайсы тамашачы иркен рәвештә катнашып

китә ала. Тамашачылар белән чыгыш ясауның менә шулай үзара берләшеп китүе бәйрәмнең, чын-чыннан халыкчан һәм демократик табигатен билгели.

Хәзерге Сабантуйлар программасында көч һәм зирәклекне, акылны сынауга корылган спорт ярышлары да, әйтик, гер яки штанга күтәрү, волейбол, шахмат һәм шашка бәйгеләре дә билгеле бер урын тота.

Мәйданда уздырылучы ярышларда, төрле урын-бәйгеләрдә җиңүгә ирешкән һәм актив катнашкан кешеләргә бирелә торган бүләкләргә аерым тукталырга кирәк. Милли көрәштә беренче урын алган батырга элек кул станогында нечкәләп сугылган һәм гаҗәеп матур итеп кулдан чигелгән кызыл башлы сөлге бүләк итә торган булганнар. Мондый сөлгеләрне, күз нурларын кушып һәм осталыгын күрсәтергә омтылып, яшь киленнәр әзерләгән. Өйдә тукыма сугу кулланыштан чыккач, буй җиткән кызлар килен булып төшкәндә, бүләккә дип үзләре чигеп, матур итеп теккән затлы күлмәк алып килә башлаганнар. Андый күлмәк шулай ук мәйданда батыр калган көрәшчегә һәм янә җайдагына дип атап, иң алдан килгән ат башына кидерелгән. Ат яратканлыктан һәм, гомумән, бәйрәмдә миһербанлык, җылы мөнәсәбәт хөкем сөргәнлектән, чабышта иң артта килгән атның ялына да махсус аталган сөлге тагу гадәте булган.

Мәйданда ярышлар тәмамлангач һәм көрәштә кемнең батыр калуы билгеле булгач, традицион Сабантуй бәйрәменең өченче этабына чират җиткән. Анысы инде заманында җыен бәйрәменә дә хас булган һәм Сабантуй бәйрәмендә сакланып дәвам иткән йола – яшь-җилкенчәкнең кичке уеннары рәвешендә узган. Яшьләр җыен һәм Сабантуй көннәрендә рөхсәт ителгән иректән файдаланып, төрле җырлы-биюле уеннар оештырганнар. Түгәрәк әйләнеп яки пар-пар тезелеп, шулай ук ике төркемгә бүленеп башкарыла торган мондый уеннар бер читтәге мәйданда, яисә, ягына карап, су яки урман, тау буенда үткәрелгән. Гадәт буенча, кайбер якларда яшьләр икенче кичне дә, кайчакта хәтта ике-өч көн рәттән күңел ачканнар, бер-берсе белән якыннан танышу, беренче мәхәббәт тойгыларының бөреләнүе һәм булачак никах мөнәсәбәтләренә нигез салыну да еш кына шушы иркенлек чорына туры килгән. Кайбер төбәкләрдә урыннарны карарга, үзләренчә яшьләргә күз-колак булырга дип, урта яшьтәге ата-аналар да килә торган булган.

Ахыр килеп, традицион Сабантуй бәйрәме еш кына сабанга чыгу, я булмаса, тиешле йолаларны саклап, беренче буразна яру йоласына барып тоташкан. Чәчүне башлап җибәрү яки буразна яру өчен ишле гаиләле ил агасы җәлеп ителгән һәм ул беренче буразнага, мул уңыш теләп, күкәйләр ташлый һәм дә сабан ашлыгы орлыклары сибә торган булган. Авыл халкы исә, яңгырлар да яусын дип, басудан кайтучыларны басу капкасы төбендә өсләренә су сибеп каршы алган. Традицион Сабантуй бәйрәменең җыйнак, әмма тулырак варианты әнә шулай тәмамланган.

Совет чорында традицион Сабантуйның җыен бәйрәме белән кушылып китүе, үткәрелү вакыты үзгәрү һәм программасының өстәмә ярышлар, бигрәк тә спорт ярышлары белән тулылануы турындагы мәгълүматны без алдарак бирдек инде. Сүз барган үзгәрешләргә өстәп, тагын шуларны әйтергә була: барыннан да элек бәйрәмнең игеннәрдән мул уңыш теләүгә

бәйләнешле сакраль функциясе кимеде һәм ул нигездә ял һәм бәйрәм итү, халыкны бергә туплау гамәленә әверелде. Бәйрәмне әзерләү һәм үткәрү исә җәмәгатьчелек башлангычыннан рәсми оешмалар, шулай ук махсус рәвештә төзелә торган комиссия карамагына күчте. Моннан тыш, төрле чыгымнарны күтәрешү һәм кыйммәтле бүләкләр алу өчен югарыдан акча бүленү дә гамәлгә керде.

Бәйрәм программасында да яңа үзгәрешләр барлыкка килде. Әйтик, бәйрәмне флаг күтәрү һәм рәсми котлаулар, шулай ук авыл хуҗалыгы алдынгыларын бүләкләү белән ачып җибәрү, кунаклар һәм читтән килгән делегацияләр кабул итү, эстрада артистлары катнашында концерт күрсәтү. Хәзерге бәйрәмнәрдә милли көрәш, катнашучыларның авырлыгы исәпкә алынып, махсус белемле спортчы судьялар тарафыннан алып барыла. Әлбәттә, мондый үзгәрешләр постсовет чорына да кагыла. Хәзерге чорда Татар конгрессының әзерлек-өйрәтү курслары оештырып, республикабыздан читтә яши торган татарларга Сабантуй бәйрәмнәре үткәрүдә якыннан торып ярдәм итүен аерым рәвештә күрсәтеп китәргә кирәк.

Региональ һәм өлкә Сабантуйларыннан тыш соңгы елларда «Федераль Сабантуйлар» үткәрү гамәлгә кереп бара. Мондый югары дәрәҗәле бәйрәм татарлар яши торган Саратов, Тольятти, Йошкар-Ола, Түбән Новгород, Әстерхан һәм Ижау шәһәрләрендә булып узды. Аларда Россиянең төрле төбәкләреннән килгән күп делегацияләр катнашты. Һәм иң истәлеклесе – Федераль Сабантуйның «Канатлы тулпар» күчмә символик сыны эшләнеп, төбәктән-төбәккә күчеп йөрде.

Билгеле, халкыбызның ил күләмендә танылган бәйрәмен әзерләү һәм уздыруда җитешсезлекләр дә юк түгел. Мәсәлән, спорт ярышларын күпләп кертү белән мавыгу, хәтта, хак булса, самолеттан парашют төшерүгә кадәр барып җиту – әлеге бәйрәмнең милли рухы белән яраша алмый. Бәйрәм барган җирдә сәүдә оешмаларының яшерен рәвештә исерткеч эчемлекләр сату белән шөгыльләнү фактлары да бар. Белүебезчә, традицион Сабантуй бәйрәмен ислам дине кушканча, татарларның һәрчак аек килеш каршылаулары бәхәссез. Шуңа күрә дә сугыш-гауга һәм тәртип бозулар бәйрәм атмосферасы өчен хас булмаган. Аннары килеп, кәмит ясыйм дип, соңгы дәвердә кулланылышка кертелгән гамәлләр арасында эстетика һәм санитария таләпләре белән ярашмый торганнары да бар. Мәсәлән, йөзең белән катык эченә чумып, телең белән шунда салынган тәңкәне – вак акчаны эзләү. Шунысы да бар: халык ризыкны шул рәвешле әрәм-шәрәм итүне хупламый. Яки менә хәтта авыл җирендә дә көрәштә батыр калган әзмәвердәй иргә традициягә каршы барып, сарык тәкәсе урынына микродулкынлы мич яки чәй сервизы бүләк итү һич тә урынлы түгелдер.

Сүземне йомгаклап, атаклы Сабантуй бәйрәменең киләчәктә дә милләттәшләребезне шатландырып һәм бергә туплап яшәвен, озын гомерле булуын телим.

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы, профессор

Мирный бистәсендәге
Каенлыкта Сабантуй.
Казан, 2019 елның 23 июне.
Татарстан Республикасы Президенты
рәсми сайтыннан

Самара өлкәсенең Гали авылында
X Бөтенроссия авыл Сабан туе.
2019 елның 29 июне.
Татарстан Республикасы Президенты
рәсми сайтыннан

Татарстан Республикасы
Милли музее фондларыннан

Фәнис Яруллин

Бүген бездә Сабантуй

Бүген бездә Сабантуй,
Эшләреңнең барын куй.
Тизрәк йөгер мәйданга:
Бәйрәм башлана анда.

Кемдә нинди һөнәр бар?
Йөгерергә кемнәр бар?
Кызганмый табаннарны
Узыгыз мәйданнарны.

Ә көрәшә кайсыгыз?
Көч сынашып кайтыгыз,
Курыкмагыз егылудан,
Йөгереп артта калудан.

Ансыз булмый Сабантуй,
Колагыңа киртеп куй.
Булмаса һөнәрегез,
Читтән карап йөрегез.
Картлар чүлмәк ватканын,
Көрәшчеләр бер-берсен
Җилкә аша атканын.

Карасагыз – бәйрәм бар.
Сусасагыз – әйрән бар.
Ял итәрсез – арсагыз,
Үкенмәссез – барсагыз.

Абрек Абзгильдин.
«Музыкантлар» савыты. 1978 ел.
«Сабантуй» циклыннан.
Татарстан Республикасы
Дәүләт сынлы сәнгать музее

Сабан туе
Безнең бәйрәм

Сабан туе
Безнең бәйрәм

САБАН ТУЕ – БЕЗНЕҢ БӘЙРӘМ

(Бәйрәм логотибы турында)

Татар Сабантуйсыз булдыра алмый ул…

Ерак бабаларыбыздан килгән милли бәйрәмебез бүген дә үзенең миллилеген, асылын югалтмый. Бу үзенчәлекне саклауда, әлбәттә, халкыбызның – җитәкчелекнең һәм киң җәмәгатьчелекнең роле зур. Ә инде Сабан туеның бизәлешенә, символларына килсәк, колга башына бәйләнгән яшь килен сөлгесеме, яисә чабышкылар муенына бәйләнелүче яулык яки кулъяулык дисеңме, һәрберсендә халкыбызның милли бизәкләре чагыла.

2020 елда республика Сабан туеның яңа логотибы булдырылды. Дөресрәге, бәйрәмнең милли бизәкләре дизайн карашыннан чыгып яңартылды, бәйрәмнең төп асылын ачып бирүче макетлар да бастырылды. Логотипның авторы – «Mardesign Заманча этник дизайн студия»се җитәкчесе Айдар Мәрдәншин.

Сабан туе – милли мәдәниятебезне яктыртучы маяк ул. Сабан туен – татар халкыннан, татарны Сабан туеннан аерып карап булмый, чөнки ул дәверләрне тоташтыра, дөньяның төрле почмакларына сибелеп яшәүче татарларны берләштерә, милли тамырларыбызга кайтара. Бу үзенчәлек логотипта «Сабан туе / безнең бәйрәм» слоганы буларак чагылыш тапкан.

Логотипның төп график билгеләре булып лалә чәчәге, татар читеге, милли көрәшне чагылдыручы ике баһадир (анысы да лалә чәчәге сурәтендә бирелә), Сөембикә манарасы сурәте һәм таҗсыман орнаментлар, түгәрәкләр, пар чынаяк, кашкарый чәчәге тора. Милли бизәкләр, калейдоскоп кебек, республикада уздырыла торган бәйрәмнең төрлелеген, мәгънәсен үз эченә җыйган: татарларга хас кунакчыллык һәм муллык, күмәк уен формалары, халык биюләре, җирлек ягъни локаль үзенчәлек һәм башкалар. Гомумән, татар орнаментында күп төслелек һәм төрлелек өстенлек итә. Мәсәлән, үсемлек орнаменты сәнгатьнең һәр өлкәсендә дә киң таралыш алган. Аеруча чәчәк мотивларының күплеге, аларны сурәтләүдәге төрлелек һәм элементлар арасында гаҗәеп дәрәҗәдә бай сәнгатьчә бәйләнеш таң калдыра. Чыннан да, лалә чәчәге, таҗсыман орнаментлар, түгәрәкләр, кашкарый чәчәгенең яшел, куе яшел, сары, кызыл яисә куе кызыл төсләрдәге контрасты чәчәк композициясендә үзара

Сабан туе
Безнең бәйрәм

Сабан туе
Безнең бәйрәм

гармония тудыра. Шулай ук, Сөембикә манарасы һәм татар читеге сурәтләре дә сары-алтын төсләрдә бирелеп, үзенчәлекле гамма хасил итә. Логотипта кулланылган һәр орнамент, бигрәк тә төсләр гаммасы татар халкына хас тыйнаклык, сабырлык, тырышлык кебек сыйфатларны ача.

Логотипның урта бизәге – лалә чәчәге. Татар сәнгатендә лалә чәчәге – яңарыш символы, орнамент буларак аның белән йортларны, мәчетләрне бизәгәннәр, ул милли кием-салымда еш очрый. Ислам дине кабул ителгәнче лалә чәчәге, күчмә чор элементы буларак, уңышлы нигезләнү, тернәкләнеп китүне белдергән. Бу символ һәр дәвердә үзенең актуальлеген югалтмый, мәсәлән, 1920 елларда ук лалә чәчәкләре белән бизәлгән читекләр чит илләргә – Франциягә, Германиягә, хәтта Америкага да җибәрелгән. Соңрак, лалә чәчәге Татарстан гербында милләтебезнең, мәдәниятебезнең, республикабызның үсешен күрсәтүче символ буларак үз урынын алды.

Лалә чәчәге кырыенда урнашкан һәр элемент ассиметриядә бирелгән. Кашкарый чәчәге бизәкнең өске өлешендә урын алган. Чәчәк уртасында буш урын түгәрәк, шулай ук татар орнаментының төп график билгеләреннән санала. Логотип үзе дә геометрик фигура формасында ромб рәвешендә ясалган.

Макетларда кулланылган фон, шулай ук, татар сәнгатендәге күптөрлелек белән бәйле. Милли киемнәрдә дә өстенлек күбрәк яшел, сары, шәмәхә, зәңгәр, куе кызыл һәм кызыл төсләргә бирелә. Логотипта кулланылган кара төстәге фон дизайн буларак «Кечке Сабан туе» бәйрәмен уздырганда отышлы. Быел бу макет «Кичке Сабан туе» бәйрәменең, онлайн «Кичке уен»ның логотибы буларак үзен аклады инде. Кара төстәге фон, бер яктан, ул төсләр гаммасын ачса, икенче яктан кайбер төсләрнең камашуын сүлпәнәйтә төшүен ассызыкларга кирәк.

Логотип ул бербөтен символ. Фон һәм орнаментларының төсен урынсыз үзгәртү логотипка салынган төп мәгънәгә зыян да китерергә мөмкин. Төсләрдәге үзара тәңгәллек бу логотипның нигезен тәшкил итә. Орнаментларны кызыл, яшел, куе яшел кебек бер төсләрдә аерым куллану, бигрәк тә футболка, сумка, төрле өс киемнәренә төшергәндә генә үзен аклый, ди белгечләр. Димәк, логотипны кулланабыз икән, аны дөрес һәм урынлы итеп куллана белү дә бик мөһим.

«Бу логотипны бренд дәрәҗәсенә үстерү өчен бөтен алшартлар да бар. Мәскәү, Казан, Европада үткәрелүче Сабан туеның логотибын ясау тәҗрибәсен истә тотып, мин курыкмыйча әйтә алам, бу логотип Казан Сабан туеның бренды булырга тиеш. Бу логотипны куллану, киемнәргә төшерү, төрле форматларга күчерү бик җиңел», – ди логотип авторы Айдар Мәрдәншин.

Дөрестән дә, бу бәйрәм бөтен татарныкы, әмма аны безнең җирлектән, Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәреннән аерып карап булмый.

Рәмзия ГАЙФЕТДИНОВА,
фәлсәфә фәннәре кандидаты

Сувенирная продукция
Сабан туе
Безнең бәйрәм

Сабан туе

Сабан туе
Безнең бәйрәм

Сабан туе
Безнең бәйрәм

Сабан

Сабан
туе

Сабан
туе

Сабан туе таңнары

Ирек Сабиров сүзләре,
Равил Газизов көе

Керфегемне назлап сөйде
Нуры җәйге шәфәкънең.
Күзләремне мендәремнән
Күтәрдем дә, шаккаттым.

Кушымта:
Сабан туе нигъмәтләре
Бизәп тора өстәлне.
Әллә бу ал пәрәмәчләр
Түтәлләрдә үскәнме?
Һич юк! Безнең әниебез
Торып иртүк эңгердән,
Мичне ягып, бәлеш куеп,
Сыер савып өлгергән.

Кушымта.

Үтүкләгән ак күлмәген,
Чиста, пөхтә, сөйкемле.
Әнә яңа кәләпүшем
Көтеп алган бу көнне.

Кушымта.

Иртүк күзен тырнап ачкан
Авылдагы һәр сабый.
Колга тотып, сөлге җыеп
Йөри Габдери абый.

Кушымта.

Кояш, моңнар, өстәлләрнең
Бәлешләре-баллары.
Менә шулай истә калган
Сабан туе таңнары.

Шамил Шәйдуллин.
«Минем авылымда бәйрәм. Сабантуй».
1978 ел. Татарстан Республикасы
Дәүләт сынлы сәнгать музее

CR

САБАНТУЙ БӘЙРӘМЕНЕҢ ТӨП КОМПОНЕНТЛАРЫ: милли уеннар һәм ярышлар

Иҗтимагый-мәдәни тормышта билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләр тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү – барлык халыкларга да хас булган гомуми күренеш. Ул мәдәниятнең мөһим бер элементы булып исәпләнә һәм аның аермачык этник төсмердә булуы, халыкның бик тирәндә яткан сыйфат хасиятләренә бәйләнгәнлеге күзгә ташланып тора. Тегe яки бу халыкның үзенчәлеген аерып күрсәтәсе килгәндә, шул халыкка гына хас булган аерым йола һәм бәйрәмнәрне атап әйтмичә калмыйлар.

Әйтеп кителгәнчә, һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Ә ул бәйрәмнәрне милли уеннардан, ярышлардан башка күз алдына да китереп булмый. Без татар халкының милли бәйрәме Сабантуйда уздырыла торган уеннар һәм ярышларга тукталырбыз. Милли уеннар дигәндә, без чүлмәк вату, колгага меңү, йомырка салынган кашык кабып йөгерү, капчык сугышы, катыктан акча эзләү кебек уеннарны күздә тотабыз.

Балалар Сабан туе.
Мөслим авылы, 2017 елның 16 июле.
И. Яббаров фоторәсеме. Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

КӨЯНТӘ-ЧИЛӘК БЕЛӘН ЙӨГЕРҮ

Ярышта хатын-кызлар да ир-атлар да катнаша ала. Алар ике сулы чиләкне көянтә белән иңбашына күтәреп старт сызыгына тезеләләр. Сигнал бирелүгә, алдан билгеләп куелган арага (80-100 метр) йөгерәләр. Беренче булып килгән һәм чиләгендә суы күбрәк калган катнашучы җиңеп чыга. Бу уен билгеле бер тәҗрибә булуны таләп итә, чөнки көянтәне беренче тапкыр кулына алган катнашучы уенда җиңүгә өметләнә алмый.

Арча Сабан туе.
2019 елның 9 июне.
Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
рәсми сайтыннан

ЙОМЫРКА САЛЫНГАН КАШЫК КАБЫП ЙӨГЕРҮ

Уенда катнашучылар йомырка салынган агач кашыкларның сабын авызларына кабып 100-120 метр араны йөгереп узарга тиешләр. Кашыкка һәм йомыркага кул белән кагылырга рөхсәт ителми. Йомырка кашыктан җиргә төшсә, катнашучы уеннан чыга. Йомырканы кашыктан төшермичә, финишка беренче килүчегә бүләк тапшыралар.

Яшел Үзәннең Кече Шырдан авылындагы Сабантуй күренеше. 2018 елның 16 июле. http://yashel-uzan.ru/news/yash%D3%99esh/chyn-sabantuy-krerg-nasyyp-buldy

АЯКЛАРГА КАПЧЫК КИЕП ЙӨГЕРҮ

Уенда катнашучылар аякларына капчык кияләр һәм капчык авызын куллары белән җыеп тоталар. 100 метр араны сикерә-сикерә яки вак-вак атлап узарга кирәк. Иң беренче финишка килгән катнашучы җиңүче дип игълан ителә.

Арча Сабан туе.
2019 елның 9 июне.
Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
рәсми сайтыннан

КОЛГАГА МЕНҮ

Җиргә 10-15 метр озынлыктагы шома колга утыртыла. Аның очына сөлге, флаг яисә берәр бүләк элеп куела. Иң тиз арада колгага үрмәләп менеп бармаклары белән бүләккә кагылган кеше җиңүче була. Уенда катнашучылар бернинди җайланмалардан да файдаланырга тиеш түгел. Колга очына берничә кеше менеп җитүе дә ихтимал. Җиңүчене билгеләү өчен кемнең күпме вакыт аралыгында менгәнен секундомер белән ачыклыйлар.

Саклану чарасы буларак катнашучыларның билләренә нык аркан бәйләнә.

Колгага менү.
Казан, датасы күрсәтелмәгән.
Татарстан Республикасы
Дәүләт архивы фондларыннан

АВЫШ БҮРӘНӘ ӨСТЕННӘН ЙӨРҮ

4-5 метр озынлыгындагы бүрәнәнең бер очы җирдән 1-1,5 метр биеклектә беркетелә. Уенда катнашучылар, шул горизонталь бүрәнә буйлап чиратлашып үтеп, аның башына элен-гән бүләкне алырга тырышалар. Ярыш урынын әзерләгәндә бүрәнә астына гимнастика келәмнәре җәелә.

Бу уенның икенче варианты да бар. Авыш бүрәнә елга ярына беркетелә. Уенда катнашучы-лар шул горизонталь бүрәнәнең очына барып җитәргә тиеш. Кайбер уенчылар, максатка ирешә алмыйча, суга чумарга мәҗбүр булалар. Бүрәнәнең очына барып җиткән катнашучыга бүләк тапшыралар.

Буа Сабан туе.
2019 елның 10 июне.
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
рәсми сайтыннан

КАПЧЫК СУГЫШЫ

Ике уенчы озынлыгы 3 метр булган һәм 1-1,2 метр биеклеккә беркетелгән бүрәнәгә атланып утыра. Аларга салам яки печән тутырылган капчыклар бирелә. Сигнал булуга, катнашучылар, капчык белән сугып, бер-берсен бүрәнәдән бәреп төшерергә тырыша. Көндәшен бәреп төшереп, үзе егылмыйча калган кеше җиңүче була. Уен барган чакта буш кул белән бүрәнәгә тотыну тыела!

Ярыш урынын әзерләгәндә бүрәнә астына гимнастика келәмнәре җәелә.

Мирный бистәсендәге
Каенлыкта Сабантуй.
Казан, 2018 елның 23 июне.
Татарстан Республикасы Президенты
рәсми сайтыннан

ЧҮЛМӘК ВАТУ

Бу уенны уздыру өчен чүлмәк, 150-200 сантиметрлы таяк кирәк була. Уенда катнашучының күзләрен яулык яки сөлге белән бәйлиләр, кулына таяк тоттыралар. Катнашучыдан 10-15 метр аралыкта чүлмәк куела. Уенчыны бер урында өч тапкыр әйләндерәләр. Уенда катнашучы чүлмәкне табып аңа таяк белән сугарга тиеш. Чүлмәк ватучыга бүләк бирелә.

Ульян Сабан туе.
2019 елның 15 июне.
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
рәсми сайтыннан

АРКАН ТАРТЫШУ

5-8 метр озынлыгындагы арканның ике очына зур элмәк ясыйлар. Ике уенчы шул элмәкне җилкәләренә кияләр дә, як-якка китеп җиргә тезләнеп тартыша башлыйлар. Уенда катнашучыларның берсе икенчесен билгеләнгән сызык аркылы өстерәп чыгаргач уен тәмамлана.

Тартышкан вакытта аягүрә басарга һәм чит әйберләргә кул белән тотынырга рөхсәт ителми.

Ульян Сабан туе.
2019 елның 15 июне.
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
рәсми сайтыннан

ТАЯК ТАРТЫШУ

Ике уенчы аяк табаннарын бер-берсенә каршы куеп җиргә утыралар. 1-1,5 метр озынлыгындагы 3 сантиметр юанлыгындагы таякка тотынып тартыша башлыйлар. Кайсы уенчы көндәшен җирдән күтәрә ала, шуңа бүләк бирелә.

Апас Сабан туе.
2019 елның 10 июне.
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
рәсми сайтыннан

КАТЫКТАН АКЧА ЭЗЛӘҮ

Тирән эчле табакның төбенә катык һәм тимер акча салалар. Уенда катнашучыларның кулларын артка бәйлиләр. Шул рәвешле уенчылар телләре белән катыктан тимер акчаларны табарга тиешләр. Кем беренче табып чыгара, шул – җиңүче.

БҮЛӘКНЕ КИСЕП АЛУ

Бүләкләрне җеп белән ике колга арасына тартылган бауга элеп куялар. Уйнаучыларның күзен бәйлиләр дә кулына кайчы тоттыралар. Ул бауга эленгән бүләкне кайчы белән кисеп алырга тиеш. Кул белән бауга һәм бүләкләргә кагылырга рөхсәт ителми.

Катыктан акча эзләү.
Кукмара, 2018 елның 18 июне.
https://kukmor-rt.ru/photo/borba-kuresh-skachki-i-moneta-v-katyke-kak-proshel-sabantuy-v-kukmore.

МИЛЛИ КӨРӘШ

Татар халкының иң яраткан ярышларыннан берсе – милли көрәш. Аның озын тарихы һәм үзенә генә хас традицияләре бар. Шуңа күрә дә Сабан туе батырлары халык арасында хөрмәт казана һәм аларга һәрвакыт кыйммәтле бүләкләр тапшырыла. Тамашачыларның көрәшне зур кызыксыну белән карауларын күздә тотып, аны бәйрәмнең финал өлешендә үткәрәләр һәм мәйдан тотарга батырлар чыккач, бүтән уеннарны туктатып торалар[1].

Сабантуйларында көрәшне үткәрү өчен баш судья итеп, гадәттә җирле үзидарә рәисе билгеләнә. Аңа ярдәмгә көрәшне яхшы белгән судья алына. Алар үзләре янына секретарь,

[1] Шәрәфетдинов Д.Р. Татар барда – Сабан туе бар. – Казан: «Гасыр», 2003. – Б. 434.

Самара өлкәсенең Гали авылында
X Бөтенроссия авыл Сабан туе.
2019 елның 29 июне.
Татарстан Республикасы Президенты
рәсми сайтыннан

Арча Сабан туе.
2019 елның 9 июне.
Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
рәсми сайтыннан

келәмдәге судья (арбитр), ян-як судьялар һәм табиб алалар. Бу бригада низаг чыкмасын, ә чыга калганда гадел юл белән хәл итү өчен үзенә авылның, районның ихтирамга лаек, зур тәҗрибәле картларын алырга тиеш. Шушы бригада көрәштә катнашырга теләгән ир-егетләрне бергә туплый. Көрәшчеләр келәмгә табиб рөхсәтеннән башка чыга алмый.

Татарча көрәш, соңгы еллардагы кагыйдәләр нигезендә, тугыз үлчәүдә үткәрелә. Сабантуйларда исә күпме көрәшче җыелуга карап, аларны төрле үлчәү авырлыкларына бүлеп көрәштерү каралган. Һәр үлчәү авырлыгында аерым-аерым шобага салына. Бу болай эшләнә: үлчәү авырлыгында ничә көрәшче булса, шулкадәр номер язып, аларны бөкләп, судьяның түбәтәенә салалар. Шуннан һәр көрәшче үзенең номерын ала. Шул номерлардан чыгып, судья белән секретарь исемлек төзеп чыга.

Катнашучылар бик күп булганда очрашуларны олимпия системасы буенча, ягъни оттырган кеше шундук төшеп калырлык итеп үткәрәләр. Судья белән секретарь кемгә ничәнче номер

Буа Сабан туе.
2019 елның 10 июне.
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
рәсми сайтыннан

Canon

чыга, аларны исемлеккә шул тәртиптә язып куя. Шуннан соң 1 нче номер белән 2 нче, 3 нче белән 4 нче очраша. Беренче әйләнештән соң бөтен көрәшченең яртысы гына кала. Очрашулар шул ук тәртиптә, исемлектәге күрше белән күршенең очрашуы төсендә дәвам итә.

Өч кенә кеше калганда яисә «батырлар тотышы» да уздырырга була, ягъни арбитр финалга чыгучыларга бау тоттыра. Көрәшчеләрнең өчесе дә бауга чиратлап башта бер, аннары икенче кулы белән тотына да, бауның очына җиткәнче тотышны эзлекле рәвештә алмаштырып бара. Бауның очында – 2 нче, башка чыгучы – 1 нче, ахырга калучы 3 нче номер санала. Шуннан чыгып, 1 нче белән 3 нче номерлар көрәшә, 2 нче бу вакытта ял итә. Аннан соң җиңүче як 2 нче номер белән 1 нче һәм 2 нче урыннарны бүлешү өчен көрәшә. Аңа кадәрге очрашуда җиңелүчегә 3 нче урынны бирәләр.

Сабантуйда катнашучылар күп булганда көчлерәк көрәшчеләрне төрле урыннарга таратып, берничә төркемгә бүләргә дә ярый. Андый чакта үз төркемнәрендә җиңеп чыгучылар ярымфинал һәм финал төркемен оештыралар. Алар арасында яңадан шобага салына.

Көрәш башланыр алдыннан судья көрәшчеләрнең икесен келәмнең ике ягына чакыра. Баш судья аларның кайдан, кем булулары белән таныштыргач келәмдәге арбитр сыбызгы сызгыртып, аларны уртага дәшә. Шуннан соң гына алар билбауларын бер-берсенең билләренә салалар.

Көрәшү өчен киңлеге 40-45 сантиметр, озынлыгы 110-115 сантиметр сөлге алына. Ул бер ягын озынрак калдырып, уң кулының беләзегенә (сулагайның сул кулына) салына. Кыска башы аста кала. Сөлгенең озын ягы баш бармак белән имән бармак арасына кысып тотыла. Болай иткәндә ул кулдан берничек тә шуып чыкмый. Гадәттә өлкән көрәшчеләр сөлгене бил өстенә ике кул арасына 20-25 сантиметр калдырып тота. Яшьләр өчен сөлгене 15-16 сантиметр чамасы тоту уңайлырак.

Арбитр ике якның да әзерлеген тикшерә һәм сыбызгысын икенче тапкыр сызгыртып, көрәшә башларга боера. Көрәш олылар арасында – ун минут, 17-18 яшьлекләр арасында – сигез, 15-16 яшьлек үсмерләр арасында алты минут дәвам итә. Олылар биш минуттан соң, үсмер 3-4 минут көрәшкәч, берәр минут ял итәләр. Сөлгене билгә бәйләп тә, бәйләмичә дә көрәшергә мөмкин. Анысы кайсы якта нинди традицияләр булуга бәйле. Ә болай, гадәттә, вакытның беренче яртысын сөлгене бәйләмичә, ә бер минутлык ялдан соң сөлгене билгә бәйләп көрәшү кулланыла.

Әгәр көрәшче көндәшен җирдән (келәмнән) күтәреп, күкрәге, янбашы аша аркасына ташлый икән, аңа «саф/чиста җиңү» бирелә. Тик «саф җиңү» бирү өчен бригададан кимендә ике судьяның риза булуы кирәк. Моннан тыш, көрәшче баллар буенча өстенлеккә ирешеп, аның көндәше җәрәхәтләнеп, көрәшне дәвам иттерә алмаса, яисә судьялар тарафыннан ярыштан чыгарылса, көрәшчеләрнең берсе югары бәяләнерлек алымнар күрсәткәндә шулай ук «саф җиңү» бирелә[2].

---

[2] Мулланұров Мөхәммәтнур. Сабантуй бәйрәмен үткәрү тәртибе. Сценарий. – Казан, 1997. – Б. 27-30.

АТ ЧАБЫШЫ

Сабантуйның тагын да дәртләндерә, дулкынландыра торган күренеше – ат чабышы. Атны чабышка алдан әзерлиләр. Күнектерү алымнары, туклану режимы билгеле бер тәртиптә бара. Узыш көне җитәр алдыннан мал тынычсызлана, кешнәве дә башкача, кайнарланып йөри, баскан урынында бии башлый. Бу атларның ни дәрәҗәдә акыллы булуы, бәйгене җитди кабул итүе хакында сөйли. Бәлки шуңадыр да еллар дәвамында Сабан туенда атлар чабышы иң зәвыклы, затлы, дулкынландыргыч тамаша булып кала бирә. Ярышлар бик җитди һәм кызык уза.

Әлеге ярыш өчен тигез юл сайлап алына. Дистанциянең озынлыгы төрлечә – 3, 5, 8, 10 һәм 12 километр була. Финиш исә бәйрәмне үткәрү урынына якын булырга тиеш.

Чабыш башланырга 60 минут кала, судьялар коллегиясе рупордан бәйгенең программасын, барлык катнашучыларның санын, һәр катнашучының исем-фамилиясен, ат кушаматларын игълан итә. Ярыш башланыр алдыннан 20 минут кала, судьялар коллегиясе кыңгырау чыңы белән катнашучыларга атны әзерләү кирәклеге турында хәбәр итә.

Чабышта катнашучылар стартта 30х20 сантиметр зурлыктагы күкрәк номерлары асалар һәм атларын, 1,5-2 метр ара калдырып, тигез рәткә тезәләр. Судьяның сигналы булуга, атлар урыннарыннан кузгала. Беренче килүче җиңүче була [1].

[1] Муллануров Мөхәммәтнур. Сабантуй бәйрәмен үткәрү тәртибе. Сценарий. – Казан, 1997. – Б. 34.

Самара өлкәсенең Гали авылында
X Бөтенроссия авыл Сабан туе.
2019 елның 29 июне.
Татарстан Республикасы Президенты
рәсми сайтыннан

ГЕР КҮТӘРҮ

Бу төр ярышларда 17 яшьтән дә ким булмаган ир-егетләр катнаша. Ярышны үткәрүдә табиб, санаучы судья, вакытны исәпләүче судья катнаша.

Ярышны үткәрү урыны буйга да, иңгә дә 2 метр күперчектән тора. Аңа келәм җәяргә мөмкин. Күперчекнең уртасына гер куела. Гер күтәрүчеләр ярышы герне бер кул белән әкренләп күтәрүдән башлана. Ярышчы аяк очларын бер сызыкка турылап баса да герне күкрәгенә ала. Санаучы судья старт биргәч, вакытны исәпләүче судья сәгатен (секундомерын) җибәрә, ә ярышчы герне әкренләп баш очына күтәрә. Кулны өскә сузып турайтуга, ул герне тотып торган килеш судьяның санаганын көтәргә тиеш. Шуннан соң гына гер яңадан күкрәккә төшерелмичә аска — ике тез арасына төшерелә һәм күтәрү дәвам итә. Бер кулы арыгач, ярышчы герне күперчеккә төшермичә генә икенче кулына күчерә һәм күтәрүне дәвам итә. Ләкин ул бу кулы белән тегесеннән артык күтәрергә тиеш түгел, ягъни ике кулы белән дә бер үк санда күтәрергә тиеш. Шуңа да, гадәттә, ярышчы күтәрүне көчсезрәк кулы белән башлый. Бу күнегүне башкарганда аяклар тездән бөгелмәскә, гәүдә бер якка авышмаска, аяк табаны күперчектән аерылмаска, гер күкрәктән түбән төшмәскә тиеш.

Герне бер кул белән кинәт күтәргәндә («рывок») аяклар да, гәүдә дә туры торырга тиеш. Бу адымны башкарганда да герне күперчеккә куярга, әкренләп күтәрергә яисә буш торган кул белән гергә, күперчеккә, икенче кулга, аякка, гәүдәгә кагылырга ярамый.

Ярышчы шул таләпләрне бозган очракта санаучы судья «Санамаска!» күрсәтмә бирә. Ярыш таләбе өч мәртәбә рәттән үтәлми икән, ул чакта санаучы судья «Туктарга!» боера. Мондый команда ярышчы герне күперчеккә яисә гәүдәсенең тыелган өлешенә тидергән очракта кисәтүсез дә яңгырый һәм ярышчыны урыннан мәхрүм итә. Чөнки күтәрү алымнарының берсен генә башкарганда да нуль билгесе алган ярышчы ярыштан төшеп кала.

Судья чакыргач, 2 минут буе күперчеккә чыкмый торса яисә чыгып та күтәрергә әзерләнеп бетә алмаса, ярышчы шулай ук ярыштан чыгарыла.

Әгәр дә команда вәкиле судьяларның мондый карары белән риза булмый икән, күперчеккә башка ярышчы чыкканчы баш судьяга мөрәҗәгать итә ала. Телдән бирелгән бу протест тикшерелеп, бер карарга килгәнче ярыш туктатылып тора.

Герне кинәт күтәргәндә (ике кулда да башкарылган «рывок») һәм ике герне ике кул белән («толчок») бер мәртәбә күтәргән өчен ярышчыга 1 әр очко языла.

Шушы ике төрле адым белән күтәреп иң күп очко җыйган ярышчы җиңүче дип табыла. Берничә ярышчының очколоры тигез булса, беренчелек җиңелрәк үлчәүлесенә бирелә. Күрсәткечләре ул яктан да тигез булган очракта, өстенлеккә ике герне ике кулы белән күбрәк күтәрүче ирешә.

КУЛ КӨРӘШЕ

Әлеге спорт төре көчле, чыдам кешеләр өчен. Уен кагыйдәләре бик гади: көндәшне җиңәр өчен, аның кулын махсус мендәр куелган өстәлгә басарга кирәк. Әмма спортчыларның башы, гәүдәсе, җилкәсе өстәлнең үзәк сызыгын узарга тиеш түгел. Көрәшче терсәген өстәлдән, ике аягын идәннән алса, баш, җилкә, гәүдәсе белән өстәлнең урта сызыгын узса аңа кисәтү ясала.

Кисәтү игълан ителгән очракта, катнашучыларга 30 секунд тәнәфес бирелергә мөмкин. Спортчыга икенче кисәтү ясалса, җиңелү игълан ителә. Ике тапкыр җиңелгән катнашучы уеннан чыгарыла.

Сабантуй – тарихы бик тирәннәргә, әллә-ничә мең елларга җиткән, гасырлар буена үзенең әһәмиятен югалтмаган мәдәни байлык. Мәйданда уздырылган милли уеннар, ярышларны өйрәнү, популярлаштыру әлеге халык бәйрәмен, татар милләтен таныту, аның рухи бердәмлеген, мәдәниятен, телен саклау чарасы булып тора.

Язманы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең фәнни хезмәткәрләре Динара ФӘРДИЕВА, Филүзә МӘРДАНОВА әзерләде

Түбән Наратбаш авылы Сабан туе.
2019 елның 9 июне.
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
рәсми сайтыннан

Роберт Миңнуллин

Сабантуй бүген бездә!

Шатлыклар – күңелебездә,
Ал кояш – күгебездә,
Килегез, дуслар, кунакка,
Сабантуй бүген бездә!

Иң уртага утыртканнар
Иң озын бер колганы –
Колганың да бик тиз генә
Менеп булмый торганы.

Җиңгиләр биреп җибәргән
Бизәкле бүләкләрен,
Ә малайлар көрәшергә
Сызганган беләкләрен!

Ә кызлар киеп чыкканнар
Иң матур күлмәкләрен.
Латыйп бабай төяп килгән
Иң ныклы чүлмәкләрен.

Абыйлар алып килгәннәр
Иң җитез юртакларын.
Гармунчылар алып чыккан
Җырларның уртакларын.

Җилферди чиккән сөлгеләр,
Бүләкләр – күбебезгә!
Көрәшик тә, узышыйк та –
Сабантуй бүген бездә!

Шамил Шәйдуллин.
«Озын гомерлеләр». 1997 ел.
«Сабантуй» циклыннан.
Татарстан Республикасы
Дәүләт сынлы сәнгать музее

СЦЕНАРИЙ ҮРНӘКЛӘРЕ

САМАРА ӨЛКӘСЕ, ПОХВИСТНЕВСК РАЙОНЫНЫҢ ГАЛИ (АЛЬКИНО) АВЫЛЫНДА УЗДЫРЫЛГАН БӨТЕНРОССИЯ АВЫЛ САБАН ТУЕ

(29 май, 2010 ел)

Сценарий авторы – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе ***Халисә Исмәгыйлева***

(Въезд и проходы к месту проведения Сабантуя празднично оформлены, повсюду висят флажки, шары, транспаранты, символы Сабантуя, призывы и праздничные лозунги.

В звенящей торжественной тишине, разливаясь в майском воздухе, сначала из одной мечети села Алькино, затем из второй, из третьей раздается такъбир (молитва).

Костюмированные юноши – воины с саблями на высоко поднятых руках вносят огромный котел – казан – символ Казани (впереди – двое, за ними – несущие казан, затем еще двое воинов).

За воинами следуют костюмированные персонажи – жители села Алькино (возможно, участники художественной самодеятельности Похвистневского района): девушки с коромыслами, косари с косами, пчеловоды, бахчеводы с корзинами, полными плодов, пастухи с кнутами, джигиты с шестами, на которых развиваются яркие полотенца и ткани – дары жителей села и гостей Сабантуя – победителям, девушки с ведрами, наполненными яйцами.)

Алып баручы:

400 еллык авыл Гали... Яр буенда күкрәп чыккан,
Бөек Гали, изге Гали... Дүрт гасыр яшәп чыныккан.

Татарстан Республикасы
Дәүләт җыр һәм бию ансамбле.
Самара өлкәсе Гали авылында
Х Бөтенроссия авыл Сабан туе.
2019 елның 29 июне.
Татарстан Республикасы Президенты
рәсми сайтыннан

Тарихи җир, гүзәл ватан, риваятьләр тудырган җир,
Һөнәрчеләр, кәсепчеләр – муллык, байлык булдырган җир!
Киләчәккә өмет багълап, яшьләр җырлап яшәгән җир,
Иманы, шөһрәте белән күңелләрне биләгән җир!
Мөкатдәс Гали туфрагы!.. Изге җирләр ... Бөек ватан...
Тау астында, су буенда – гөлбакчадай чәчәк ата...
Килде сиңа бөек бәйрәм, суз кулларың, күңелең куй!
Галидә милләт бәйрәме, алыплар туе – **Сабантуй!**

Ведущий: Удивительна земля Самарская, невероятно богата ее природа. Горячий летний зной утоляется прохладой рек. Тянутся вдоль волжских протоков сочные заливные луга, шумит многолетний камыш. Так и наш праздник сегодня: все в нем сплелось – и зной горячих шуток, задорных плясок, смех и веселье, и речная прохлада песенной лирики, льющейся из самого сердца народа – здесь, в селе Гали.

Алып баручы: Исәнмесез, хөрмәтле милләттәшләр! Хәерле көн, кадерле Сабантуй кунаклары! Изге Болгар һәм Казан җирләреннән, татарларның тарихи ватаныннан – сезгә туганнарча кайнар сәлам!

Ведущий: Приветствуем тебя, Гали – земля фантастических кладов, прими от нас праздник нашей прекрасной земли! Из самого сердца Татарстана сердечный привет – наш самый любимый, самый задушевный праздник – наш Сабантуй!

Со всех концов России сегодня здесь собрались друзья, чтобы во время любимого всеми россиянами праздника продемонстрировать нам свои трудовые достижения, свое замечательное искусство, свою спортивную доблесть, свою удаль!

Алып баручы: Сабантуй – безнең көтеп алган зур милли бәйрәмебез. Сабантуй безнең күңелләребездә гомер буе бер тылсымлы көч булып яши. Бу көч безне туган җирдән еракларда яшәгәндә дә бертуганнар кебек берләштерә. Бу көч безне туган җиребезгә чакырып кайтара! Бу көч безнең дуслык, туганлык бакчасын сокланып туймаслык бизәкләр белән матурлый!

(Достопримечательностью села Алькино является родник, по легенде этот родник возник в том месте, где читал молитву мифологическая личность, святой старец Морат-бабай.

Две празднично одетые девушки несут серебрянный сосуд с волшебной водой абельхаят (живой водой) – водой из источника села Алькино. На празднично украшенной арбе въезжает на Сабантуй легендарный Морат-бабай.)

Ведущий:
Полна чудес история Гали,
В нем много лет назад великий старец жил.

Плеснув воды – в селе пожар тушил,
Был скромен – и величию учил...

Он посетить решил сегодня праздник наш,
Взглянуть, как сторона родная хороша,
Ведь где народ ликует и поет –
Там мудрость вечная, народная живет!

(В это время продолжается движение колонны, состоящей из нескольких всадников в болгарских костюмах, бричек. На бричках едут гармонисты, артисты, селяне. Весело проезжают они мимо трибун, обозначая приход праздника Сабантуй на землю Алькино. В составе колонны следуют спортсмены Похвистневского района Самарской области, представители национально-культурных автономий (из разных регионов России и Самарской области), лучшие коллективы художественной самодеятельности.

Морат-бабай в сопровождении девушек-артистов подходит к микрофонам, находящимся на майдане. Под музыку звучит его монолог. Имитируется шум воды.)

Алып баручы:
Менә чишмә. Аңа инде күп ел...
Намазлыгым салып, бер аятъ
Укыганым булды: су калыкты
Әбельхаят булып, ни гаҗәп!

Сулы булды авыл, саф чишмәле,
Савыктырды суы хастәне,
Тел ачкычы бирде нәүмизләргә.
Чыныктырды картны, яшьләрне.

Яшә изге чишмә тагын мең ел,
Башка бәла-каза килмәсә –
Татлы суы изге кәүсәр кеби,
Сусауларны басар, моң басар!

Фатихамны бирәм яңаруга,
Ургылуга, сукмак яруга,
Яңалыкка, киләчәккә табан.
Гөлләр өсти-өсти баруга!

Арагызда кояш кебек балкый,
Йолдыз кебек якты шәхесләр.
Бу җирләрнең магиясе көчле,
Шуңа халкы күркәм, бәхетле!

(В то время, когда звучит стихотворение, девушки-красавицы сопровождающие старца, предлагают народу испробовать священную воду.)

Ведущий:
О, старец с белоснежной бородой,
Хранитель этих мест прекрасных,
Им путь проложен для народа ненапрасный
Возвышенной молитвою святой!

Трудом, терпением он вел односельчан –
И в чистоте, любви родились дети.
Молитвы светлые заслышав эти,
Пробились к свету струи золотого родника.

Его глоток – как отдыха часы,
Уроки предков – словно птицы – сквозь столетья,
И пьют из золотого родника,
И не насытятся святыней нынешние дети!

О, вкус, о сладость чудо-родника.
Рожденного молитвами святого старика,
О вкус, о диво каждого глотка,
Молитвой в наших отзывается сердцах!

(Морат-бабай уходит за сцену.)

Ведущий: Дорогие друзья! Уважаемые гости майдана! Сегодня мы рады приветствовать всех вас на Всероссийском сельском Сабантуе – в деревне Алькино (Гали)! Отрадно то, что

этот национальный праздник приобретает все более широкий масштаб и празднуется на Всероссийском уровне.

Оглянитесь вокруг: на наш праздник пришли и стар, и млад, и, самое главное – люди разных национальностей. Пусть сегодняшний праздник плуга – Сабантуй будет праздником Дружбы, Взаимопонимания, Стабильности, Мира и Счастья! Сегодня нам выпала честь участвовать в замечательном событии – церемонии открытия Всероссийского Сабантуя! Делегации из самых разных регионов России съехались в Самарскую область.

(Торжественный фейерверк – фонтан, конфетти.)

Ведущий: А между тем, пора начинать соревнования, игры Сабантуя. И, конечно же, самое главное из них – национальная борьба – көрәш.

Алып баручы: Дуслар, чыннан да, Сабантуй уеннарына күчәргә күптән вакыт. Сабантуйның күрке – татар көрәше. Мәйданда татарча көрәш башлана.

Сабантуйларда да алга карый халык –
Көрәштерә башлый нәниләрдән алып.
Сөлгеләр тотыла, һәр кунак
Батырын күзәтә билгеле...
Көрәш кыза мәйдан уртасында,
Дулкынлана халык: кем җиңәр?
Көрәшчеләр әле бил бирмиләр,
Чыдасыннар гына сөлгеләр!

Ведущий:
Не батыры – станут ими
Эти оба молодца.
Водят мышцами стальными
Отбивая такт сердцам.
Враз метнув по полотенцу
Обхватили друг друга,
Полотенцами джигиты,
Приготовился народ
Ждать развития событий,
Продолжения каждый ждет.

Алып баручы: Кадерле дуслар, ниһаять, Сабантуй үзенең бөтен матурлыгы, көч-кодрәте белән мәйданда урын алды! Бәйрәмнең йөзек кашы булган көрәш белән беррәттән башка уеннар, ярышлар башлана.

Сәхнәдән торып, безнең сәнгать осталары – җырчы-биючеләребез, сезнең күңелләрегезне күрергә, үзләренең осталыкларын күрсәтергә әзер.

Ведущий: Время от времени мы предоставим слово комментаторам, ведь всем интересно узнать информацию из первых уст, на наших площадках развернутся жаркие баталии между лучшими атлетами России и представителями народных видов спорта.

Алып баручы: Шулай итеп спортчыларыбызга уңышлар теләп, ярышларны башлыйбыз.

Сабантуйларның саны юк!
Юк Сабантуйның яше…
Сабантуй һәрбер татарның
Йөрәк түрендә яши.

Көне җиткәч, йөрәкләрдән
Ул мәйданнарга таша.
Чишмә-чишмә куанычлар
Бәйрәм булып тоташа.

Ведущий: Глядя на выступление наших артистов, с гордостью можно сказать: «Да, сила нашего народа в его единстве, многообразии и взаимоуважении!» А наш сегодняшний Сабантуй яркое доказательство этому. А наше поле – центральное поле стадиона заполняется все новыми народными состязаниями. Приглашаем на игру **«Разбивание горшка».**

Участнику завязывают глаза, отводят от горшка на 10-12 шагов, поворачивают на 180 градусов и он самостоятельно должен найти и разбить горшок. Разбил, значит, победил. Особым талантом в разбивании горшка в 1990 году отличился в Казани первый Президент России Б.Н. Ельцин. С одного удара вдребезги разбил глиняной горшок.

Алып баручы: Кем төз суга һәм төгәл атлый белә, әйдәгез, ватыгыз чүлмәкне, алыгыз бүләкне!

Сабантуйда зур мәйданда
Чүлмәк вата бер агай.
Читтән кычкыра кешеләр:
Бир кирәген, бир, давай!

Абзыйның да сынатырга
Һич кенә юк исәбе.
Чүлмәкнең нәкъ маңгаена
Төшкән аның кусәге.

Ведущий: Следующая игра – **«Доставание монеты из катыка».**

Окунувшись лицом в тазик с катыком (кефиром), без помощи рук, нужно достать монету. Польза от конкурса двойная: можно наесться катыка и денежки заиметь. Ну, а если серьезно, то нужно иметь огромное терпение и чувство юмора, чтобы умудриться со дна посуды, наполненной кефиром, зубами достать монету. Желающие испытать себя все же находятся – на радость зрителям. В этом виде состязаний отличился наш уважаемый Владимир Владимирович Путин в 2001 году, опять же в столице Татарстана – Казани. Татарстанцы до сих пор удивляются таланту Владимира Владимировича находить деньги даже в обычном тазике с катыком.

Ведущий: Очередная игра – **«Бой мешками»**. Это как раз тот случай, когда можно драться не жалея сил. Можно и разрядку получить и подарок заслужить. Желающих приглашаем на площадку.

Алып баручы: Мәйдандагы капчыкларга салам тутырылган. Һәр ярышучының максаты – кул белән үзе утырган бүрәнәгә тотынмыйча, каршыда утыручыны капчык белән бәреп төшерергә. Мөгаен, узган гасырларда шул юл белән безнең бабаларыбызны сынаганнардыр; ат өстендә нык утыра аламы? Беренче сугу белән егылып төшмиме?

Ведущий: Дорогие друзья, а сейчас на ипподроме начинаются скачки – без этого удивительного зрелища, от которого захватывает дух – не бывает настоящего Сабантуя!

Алып баручы: Кадерле дуслар, хәзер ипподромда ат чабышлары башлана. Күңелләрне ярсыта, күзләрне куандыра торган әлеге ярышлардан башка Сабантуй була алмый. Ат чабышларын карарга рәхим итегез!

(Гости отправляются на ипподром, где их ждет удивительное зрелище – скачки.)

Ведущий: Большим украшением нашего праздника, безусловно, являются женщины. Будет нечестно, если они останутся в стороне от наших игр. Специально для них объявляем **«Бег с коромыслом»**.

Алып баручы: Кадерле дуслар, һич шикләнүсез әйтә алабыз, бүгенге бәйрәмнең бизәге – хатын-кызлар. Әгәр дә аларны уеннарыбыздан читтә калдырсак, бу дөрес булмас иде. Хәзер булачак уен – алар өчен – **«Көянтәләр белән йөгерү».**

Ведущий: Условие игры – пройти положенную дистанцию не расплескав воду. Это состязание для женщин очень полезно, особенно для молодых девушек. После таких упражнений изящная фигура и легкая походка гарантированы. Тем более, за вами наблюдают мужчины, а для кого-то потенциальные женихи. Прекрасная половина майдана, ждем вас!

Алып баручы: Уенның шарты – тиешле араны, чиләктәге суны түкмичә, башкалардан алда үтү. Бу ярыш хатын-кызлар өчен бик файдалы, бигрәк тә яшь кызлар өчен. Бу күнегүләрдән соң нәфис гәүдә, җиңел йөреш булмаска мөмкин түгел. Җитмәсә, сезне бик кызыксынып ир-егетләр күзәтә, ә бәлки булачак кияүләрдер әле. Мәйданның гүзәлләре, сезне көтәбез!

Ведущий: Испокон веков, 400 лет, в селе Алькино не угасала вера предков, не закрывались мечети, существовало и существует медресе, в котором учатся мудрости, терпимости и духовной силе молодые жители села. В этой приверженности традициям, в уважении к духовному миру человека, возможно и таится первопричина материального благополучия, новаторства, активной жизненной позиции жителей Алькино.

Алып баручы: Борын-борыннан, Гали авылында иман нуры сүнмәгән, мәчетләр ябылмаган, мәдрәсәләр яшәгән һәм яши, аларда яшьләрне гыйлемгә, сабырлыкка, рухи көчкә, зирәклеккә өйрәтәләр. Мөгаен, менә шушы традицияләргә тугрылык, кешенең рухи дөньясын хөрмәт итү, ата-бабаларыбызның мирасын саклау, Галиның бүгенге матди байлыгы, яңалыкка омтылышы, актив тормыш позициясенең нигезендә ятадыр.

Ведущий: «Аллаху акбар» – на всех языках, во всех религиях, по всему миру звучит один мотив, одна немеркнущая тема: Аллах велик – Бог един. Мы, люди, благодарны ему за все, что он для нас сотворил, и наша цель – веротерпимость, братская любовь – как объединяющая нас в народы – сила.

Алып баручы: «Аллаһу әкбар» – «Аллаһы бөек» – бу тәкъбир барлык телләрдә, барлык диннәрдә, бөтен дөнья буенча яңгырый. Һич үзгәрми, югалмый торган гыйбәрә – Аллаһы бер, ә без кешеләр аңа барысы өчен дә шөкер кылабыз; безнең максатыбыз – бер-беребезнең динен хөрмәт итү, туганлык мөнәсәбәтләрен саклау – менә шулар безне берләштерә дә инде. «Бергәлектә көч», дигән бит халык мәкале дә.

(В звенящем от смеха и веселья воздухе майдана, сначала из одной мечети села Алькино, затем из второй, из третьей раздается Азан – молитва, оповещающая о приближении времени обеденного намаза.)

Ведущий: 400 лет не меркнет вера предков, живет мечеть, и мы не могли обойти стороной тот удивительный факт, что сохранились в татарской деревне, живущей в российской глубинке, традиции древности – и освещают, и одухотворяют они сегодняшний день жителей села. И, чтобы поддержать, укрепить молодых мусульман села Алькино, мы решили провести необычный для Сабантуя конкурс – конкурс юных чтецов Корана.

Алып баручы: Галидә 400 ел буе ата-бабаларыбызның дине сакланып килә, мәчетләр яши. Россиянең ерак бер ноктасы булган авылда борынгы традицияләрнең шулай саклануы, һичшиксез, монда яшәүче халыкка карата ихтирам уята. Иман нуры аларны бүген дә саклап килә, эшләрендә ярдәм итә. Шуңа күрә дә, Галидә туып-үскән яшьләрнең рухын ныгыту, авыл халкына хөрмәтебезне белдерү йөзеннән Сабантуй өчен гадәти булмаган ярыш – Коръән укучылар ярышы үткәрергә булдык.

(Победители (3 человека) награждаются Кораном, а лучший юный чтец получает в дар ковер с изображением жемчужины татарского мира – мечети Кул Шариф.)

Алып баручы: Кадерле дуслар, Сабантуйның күп кенә уеннары үзенең гадилеге, самимилеге, дәрте белән тамашачыны көлдерә, аның күңелен күтәрә. Әмма бу гадилек беренче карашка гына. Сабантуйның һәр ярышы катнашучылардан җитезлек, тапкырлык, тизлек, сабырлык таләп итә.

Сабантуйлар илдә гөрләгәндә,
Йөрәкләрдә ярсу тыналмас.
Ярыш гаярьлеге булган кеше
Капчык эчендә дә сыналмас.

Ведущий: Один из таких конкурсов – **«Бег в мешках»**. Думается, что нет смысла объяснять условия игры – кто прибежит к финишу первым, тот и победитель. Дерзайте!

Алып баручы: Кадерле дуслар, сез әнә теге мәйданга күз салдыгызмы икән, анда 20 метр биеклектә – ничә сәгатьтән бирле әтәч утыра. Кем дә булса менеп, аны алып төшүен көтә. Сезнең арада бармы шундый җитез, җиңел кешеләр? Яңа уен игълан итәбез – **«Колга башына менү».**

Бу ярышта җиңүче колга башына тиз генә менеп, әтәчне алып төшәргә тиеш. Бу уенның үзенчәлеге тагын шунда – ярышта өлкәннәр һәм яшьләр белән беррәттән балалар да катнаша ала. Колганың биеклеге 15-25 метр булырга мөмкин. Җитезләрне мәйданда көтәбез.

Ведущий:
Шест торчит среди майдана,
Будто тонкое копье,
Полотенце реет плавно
Там – под самым острием.

Алып баручы: Кадерле дуслар, аңлашыладыр, бөтен ир-егетләр дә көрәшче булып бетә алмый. Аның өчен азарт, спортчы рухы булырга тиеш. Әмма без ир-егетләребезнең көчле затлар икәнен күрсәтергә икенче төрле мөмкинлек бирәбез. **«Гер күтәрү ярышы»**на чакырабыз.

Ведущий: Алькино (Гали) – село энергичных, сильных мужчин. Пусть женщины любуются вами. Ну, как, соревнуемся?

Алып баручы:
Гасырларның йөген күтәргәндә
Бөгелмәгәч, бер кат сыналгач,
Гер ташларын чөйгән чакта гына
Бу беләкләр, беләм сыналмас.

Чыгып бас та мәйдан уртасына
Герләр белән уйнап кара син.
Халык синең кулларыңда
Потлар очканына сокланcын.

Ведущий: Пришло время следующего, не менее интересного соревнования – **«Бег с яйцом».**

Ведущий:
Что за чудо! В ложках камни,
Да как будто на подбор.
Ложки в зубы взяли парни,
И спешат во весь опор.

Условия игры: прибежать к финишу первым, не уронив яйцо, которое находится в ложке. Не всем удается донести свою ношу, так и норовящую выскочить из ложки и разбиться. Не так-то просто бежать грациозно и быстро как лань. Зато как весело!

Алып баручы: Кадерле дуслар, уенның шарты белән таныштырабыз: кашыктагы йомырканы төшермичә, финишка беренче булып барып җитәргә кирәк. Бу бөтен кешенең дә кулын-

нан килми. Шома, түгәрәк йомырка ничек булса да кашыктан төшеп ватылырга тырыша. Төз гәүдәләрне сыгылдырып, матур һәм тиз йөгерү бик җиңел түгел, әмма, күңелле күренеш.

Алып баручы: Кадерле дуслар, бүген безнең мәйданда балалар да бик күп. Аларның уеннарны ничек кызыксынып күзәтүләрен күрү безне дә шатландыра, балаларның үзләрен мәйданга чакырырга вакыт җитте бугай.

Чираттагы ярыш: **«Авыш колга буенча күтәрелү»** Бу ярышта колга буенча, гәүдәнең тигезлеген саклап бара белергә кирәк. Колга башына җитезләр өчен бүләк эленгән.

Ведущий: Вся «соль» этого аттракциона – не терять равновесия тела, идя по столбу. В конце столба прикреплен подарок для самых ловких.

Ведущий: Следущее состязание – **«Перетягивание каната»**, команда артистов выступает против команды победителей сабантуя и жителей села Алькино (Гали).

Алып баручы:
Көрәш кызды... Колга башларына
Менеп җитте бүген кыюлык.
Хаклык батыр калды,
Мактанчыклык
Капчык тигәч, төште егылып.

Эчкерсезлек кайткан кунак булып,
Тапкырлыгы шунда, җорлыгы,
һәр кешенең җанын сыйпап йөрде
Гасырлардан килгән җыр-моңны,

Халыктагы матур гадәтләрне
Берәм-берәм җыеп еллардан,
Бер күрсеннәр әле диеп, ахры,
Дәшеп алган безне бу мәйдан.

Сөлге белән билен буып алып,
Әйләндереп җиргә салганда,
Һәр егылган көрәшчесе белән,
«Ух!» – дип куйды халык мәйданда.

Мәйдан кызды, мәйдан шау-гөр килде,
Көрәшчеләр ярсып көрәште.
Рәхмәт хисе белән батырларга
Халык мәхәббәтен өләште.

Ведущий Друзья! Останемся преданными традициям Праздника и объявим самого терпеливого, самого ловкого, самого сильного – объявляем имя Батыра Всероссийского Сабантуя-2010 по национальной борьбе – **көрәш.**

(Звучит «Марш» С. Сайдашева. Батыры под торжественную музыку выходят на середину майдана к пьедесталу почета. Девушки в национальных костюмах надевают им пояса, на которых написано «Сабантуй батыры-2010».)

Алып баручы:
Сабантуй – борынгы йола!
Бүген дә ул шул килеш!..
Шарты бер – кеше үзеннән
Үзе сорарга тиеш:

Хакым бармы соң бәйрәмгә,
Лаеклымы мин аңа?..
Гасыр арьягында туган
Бу сорау һаман яңа.

Язмышка хуҗа халыкның
Шатлыкка да хакы бар –
Ә шатлыкның Сабан туе
Дигән мәгърур аты бар.

Яңгырасын ул мәйданда,
Гөрләсен һәр йөрәктә –
Сабан туе һәр кешене
Хөр яшәргә өйрәтә.

Ведущий: Дорогие гости Сабантуя! Нынешний Сабантуй мы проводили в селе Алькино (Гали). Эстафету на следующий год принимает село Шыгырдан Чувашской республики.

Алып баручы:
Галибану, гали җирем,
Изге илем, якты җырым,
Яр буенда – ак сиреньнәр,
Дөрләп чәчәк аткан җирем!

Кара тум-тум майлы кырлар,
Шашып икмәк биргән җирем,
Яшел-алсу болыннарда
Атлар иңрәп йөргән җирем!

Бүрәнәдән алтын йортлар,
Күккә аткан моңлы җирем –
Бизәк тулы капка-йортлар,
Йолдызларны тарткан җирем!

Гали җирем, бөек җирем,
Хезмәт сөйгән яшь-җилкенчәк,
Акыл тулы сизгер картлар,
Илдә җәннәт корган җирем!

Хисап-хезмәт, яшь хәрәкәт,
Китергән илгә бәрәкәт,
Гали җире – моңа үрнәк
Бәхет – хыял тулы терәк!!!

Ведущий: Вот такой наш Сабантуй – вечный праздник земледелия. Хорошо отпразднуешь его, порадуешь, отблагодаришь Мать-природу – будет хорошим урожай. Взойдут всходы, заколосятся нивы... В довольствии пройдет зима – а там и снова весна. Снова – сев. И опять соберет нас на праздник веселый Сабантуй! До следующих встреч, дорогие друзья! С праздником вас! Будьте счастливы, и пусть вам всегда сопутствует успех!

АЛЕКСЕЕВСК БИСТӘСЕНДӘ УЗДЫРЫЛГАН РАЙОН САБАН ТУЕ

(2019 ел)

Сценарий авторы – Алексеевск районы мәдәният йортының методика бүлеге мөдире, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре ***Рәфидә Гатина***

(Музыкальные коллективы гармошкой с пенями и плясками, и девушки в национальных костюмах с хлебом солью у ворот встречают гостей праздника.)

Алып баручы:
Бәйрәм белән сезне, якын дуслар,
Күңелләр көр булсын, түгәрәк.
Һәр кешегә бәхет алып килсен,
Сабантуйлар булсын мөбарәк!
Туган илдә бүген бәйрәм,
Туган илдә бүген Сабан туе.
Әйтерсең, Алексеевск ягының бар яме бүгенге мәйданга җыелган! Сабантуйның атлар чабышы мәйданына рәхим итегез! Сабантуйлары мөбәрәк булсын, хөрмәтле милләттәшләр!

Ведущий:
Всех, кто славно потрудился,
Честь воздав большим делам.
И успеха в них добился,
Приглашаем в гости к нам!

Алып баручы: Исәнмесез, хөрмәтле райондашлар! Данлы Сабантуйның хөрмәтле кунаклары! Ерак араларны якын итеп, Сабантуй бәйрәменә кайткан якташ-кардәшләребез! Районыбызның өлкәннәре, яшьләре, бала-чагалары!

Сезне бүгенге олы бәйрәм белән чын күңелдән котлыйбыз! Сабан туе-2019 котлы булсын!

Ведущий: Дорогие друзья! Уважаемые гости! Приветствуем вас на традиционном празднике Сабантуй! Уважаемые труженики сельского хозяйства, поздравляем вас с окончанием весенне-полевых работ, желаем вам большого доброго урожая и дальнейших успехов!

Мирный бистәсендәге
Каенлыкта Сабантуй.
Казан, 2017 елның 15 июле.
О. Тихонов фоторәсеме.
https://m.realnoevremya.ru/galleries/1984

(Звучит мелодия А.Ключарева «Татарстан-мой край родной».

На майдан заходит парень с шестом с полотенцами, за ним в круг встают лошади с плугами и девушки с корзинами с зерном имитируя сев. За ним на майдан заходят коллективы и участники художественной самодеятельности с флагами.)

Алып баручы:
Котлы булсын, дуслар, Сабантуйлар,
Гөрләп үссен иген кырларда.
Сабантуйлар әле онытылмас,
Без – татарлар – исән булганда.
Бәйрәм итик әле рәхәтләнеп,
Тәмамланган язгы кыр эше.
Яшәешнең һәрбер тармагында
Бар бит игенченең өлеше.

Ведущий: Добрый день, уважаемые алексеевцы и гости! Мы рады приветствовать вас на традиционном народном празднике «Сабантуй», празднике, пережившем многие века, восславляющем напряженный труд в поле, силу, ловкость, молодецкую удаль.

Алып баручы:
Йөзләр нурлы, күңелләр көр һәрчак,
Икмәк булса көн дә табында.
Аның һәр бөртеге хезмәт белән,
Маңгай тире белән табыла.
Гасырлардан килгән бәйрәмебез
Сабантуй – ул безнең горурлык.
Безнең халык эштә, көрәшләрдә
Йөзек кашларына торырлык.

Ведущий:
Сабантуй – это настоящая жемчужина национального духа, живой неиссякаемый родник самобытной культуры татарского народа, состояние его души и прекрасная возможность для раскрытия талантов, состязание в силе, ловкости и смекалке.
Сабантуй – это сила и ловкость!
Сабантуй – это красота и удача!
Сабантуй – это традиции отцов и дедов!

Алып баручы:
Балачактан алып Сабантуйны
Көтеп ала күңел сагынып.
Тугайлар да аны каршы ала
Шау чәчәкле келәм ябынып.

Сабантуйда, бары Сабантуйда
Шундый муллык, шундый иркенлек.
Бәйрәм итә гүя бар табигать,
Тургайлар да сайрый җилкенеп.

Бәхет эзләп ерак киткәннәрне
Изге бәйрәм дәшеп кайтара.
Онытмаска кушып үткәннәрне
Хәтер төпкелләрен актара.

Ведущий:
На большом майдане, с времен уже давних,
Собирает нас вместе похожих и разных.
Татар, да и русских, мордвов да чуваш
Веселый и добрый, яркий, как солнце,
Любимый народом Сабантуй веселый наш.

Алып баручы:
Әй, Сабантуй, изге мирас булып,
Бабамнардан безгә калгансың.
Уеннарың, җыр-моңнарың белән
Күңелләрдә урын алгансың.

Зур уңышлар, муллык вәгъдә итеп,
Әй, өздереп сайрый бер тургай.
Һәр ел саен безне куандырып,
Сабантуйга дәшә ул шулай.

Ведущий:
Уважаемые труженики сельского хозяйства! Вы – наше богатство, хранители опыта, традиций, мастерства. Именно вы делаете нашу республику процветающей. Дорогие друзья! В этот праздничный день желаем вам счастья, здоровья, благополучия, успехов в вашем нелегком труде.

Алып баручы:
И, гүзәл соң безнең Сабантуйлар!
Халкым сыман, тыйнак, ягымлы,
Халкым кебек, олы, киң күңелле,
Халкым кебек, дәртле һәм моңлы!

Ведущий:
Пусть нынче будет урожай богатый,
И стол ломиться от хлебов златых!
Пусть будет радость, счастье в доме вашем,
Улыбок ярких вам и песен озорных!
С праздником вас, дорогие друзья!

Алып баручы:
Җир йөзенә ямьле нурлар өстәп,
Сабантуйлар килде җәйләрдә.
Мәйданнарны чук сөлгеләр бизи,
Кызлар бии дәртле көйләргә.
Уңыш бәйрәменең башлангычы –
Сабантуй – ул халкым йөрәге.
Менә шунда күренә дә инде,
Татарларның көчле беләге.
Көрәшләргә чыга иң батырлар,
Су китерә иң-иң уңганнар.
Макталалар басуларда эшләп,
Алдынгыга лаек булганнар.
Җайдакларга карап таң каласың,
Җилне узып ярышып чабалар.
Тирә-юньдә күзәтүче халык,
Куллар изәп озатып калалар.
Барлык милләт халкы җыелышып,
Зур түгәрәк ясый мәйданда.
Татар халкы йөзе – Сабан туе,
Шау-гөр килә бөтен дөньяда.

(Хореографическая композиция «Туган ягым гөлләр иле».)

Ведущий: Дорогие друзья! Наступают торжественные минуты. На майдан выезжает машина ГАЗ-69 с батырами, которым предоставляется право поднятия флагов: Давайте поприветствуем их. Наши передовики проезжают круг почета Сабантуя-2019.

Алып баручы:
Хезмәтчәннәр даны ерак йөри,
Үстерә ул аны елдан-ел.
Бәрәкәтле табын түрләрендә
Быел булыр тагын ашлык мул.
Вәгъдәләрен җилгә очырмаслар
Җиргә гашыйк уңган кешеләр.
Кайтыр ашлык басулардан,
Өелерләр таудай көшелләр.

Ведущий:
Здесь никаких чудес – все очень просто,
Народ привык к нелегкому труду.
Он вроде выше стал не только ростом,
И сердцем он повсюду на виду.
Он полон весь рабочего настроя,
Живет пути грядущие творя.
На празднике веселом Сабантуя
Прославим труд народа – народа богатыря.

Алып баручы:
Басуларда чәчү беткән көндә,
Өмет баглап алгы заманга.
Бәйрәм итә халкым бүген,
Сабантуйлар гөрли мәйданда.
Игеннәр мул булып уңсын! Еллар имин булсын!
Бәйрәм белән, уңган, булган, алдынгы игенчеләр!

Ведущий:
Кормильцу-поле. Хлеб, соль хлеборобам,
Для вас же сегодня, майдан – ваше поле.
Покажем же силу и волю.
Ловкость и смелость покажет наездник.
Батыр на бревне, на ковре бой одержит.

Призы и подарки пусть каждый добудет!
Сабантуй – это чудо!
Он был, есть и будет!

Ведущий: Механизаторы – батыры сева, поднявшие флаги проходят на майдан для награждения. Дорогие друзья! Давайте поприветствуем их.

Работать в сельском хозяйстве, значит отдавать земле тепло своих рук, заботу, вкладывать свою душу и талант в любимое дело. Это стало смыслом вашей жизни. Таких людей у нас немало. Вы – гордость нашего района. И сегодня вам вручаются достойные награды.

Уважаемые передовики!
Желаем вам крепкого здоровья, счастья и семейного благополучия!
Спасибо вам,
За верность выбранному пути.
Спасибо вам,
За служение земле.

А служить земле, умножать богатство хлебного поля одно из самых благородных и прекрасных дел. Удачи вам!

Алып баручы: Кадерле хезмәт алдынгылары! Сезгә саулык-сәламәтлек, шатлык, гаилә бәхете, изге эшегездә яңадан-яңа уңышлар телибез. Рәхмәт сезгә!

Ведущий: На майдан выезжают труженики полей и ферм, которые верно и преданно служат земле и сельскому хозяйству и в прямом смысле, являются главными героями сегодняшнего праздника.

Алып баручы:
Язлар килсен мул булып,
Иген уңсын кыр тулып!
Дуслар булсын һәр җирдә,
Тынычлык булсын илдә!
Бәйрәмегез котлы булсын сезнең
Кулыгызда булсын гел чәчәк!
Сез үстергән мул уңышлар белән,
Билгеләнер безнең киләчәк.

Ведущий:
Слава миру на Земле! Слава хлебу на столе!
Слава тем, кто хлеб растил! Не жалел трудов и сил!
С праздником вас, уважаемые труженики сельского хозяйства!

Ведущий: Дорогие гости, друзья! Пробудилась к началу лета природа и теперь наступает ее активный рост, поэтому и месяц называют-Хлеборост. Колосится рожь, сады наполняются бурно цветущей зеленью. Солнце поднимается высоко над небосклоном и начинает печь еще сильнее, день становится длинным, а вечер долгим и теплым.

Окружающая нас природа очень красива. Она прекрасна в любое время года. В целях сохранения окружающей среды в нашем районе проводятся акции: «Чистый берег», в селах «Чистая улица», «Лучший дворик», «Цветущий палисадник».

В 2020 году наша республика будет отмечать свой вековой юбилей – 100 летие ТАССР, а в этом 2019 году нашему родному Алексеевскому району исполнилось 55 лет.

Дорогие друзья! Поздравляем вас с прекрасными юбилеями! Пусть вместе с этими праздниками в ваши сердца войдут радость и вдохновение. Доброго Вам здоровья, счастья, благополучия, а нашему району и республике – мира и благоденствия! Пусть общими усилиями из года в год хорошеет и расцветает родная республика!

Цвети, цвети земля родная!
Частица Родины большой.
Мы красоту родного края
Поем и славим всей душой.

Алып баручы: Кадерле дуслар! Бәйрәмнәр мөбарәк, табыннар түгәрәк, эшләрегез уң, табыннарыгыз мул, йөргән юлларыгыз якты, ризыкларыгыз татлы булсын!
Яшик әле, бергәләшеп,
Алексей бистәсендә.
Җырлап-биеп күңел ачыйк
Сабантуй иртәсендә.

Ведущий: Дорогие друзья! Всех нас ждут зрелищные игры, конкурсы, соревнования: национальная борьба-көрәш, лазание на шест за петухом, поднятие гири, бег с яйцом на ложке, перетягивание каната, бег в мешках, армрестлинг, разбивание горшков, волейбол, пляжный волейбол, срезание призов, бой с мешками, бег с коромыслом, ходьба по наклонному шесту, конкурс «Найди монету в катыке», перетягивание палки, стритболл, распилка дров, супергородок, футбол, бадминтон, батуты и качалки для детей.
Добро пожаловать на состязания!

АРЧА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ

АРЧА ШӘҺӘРЕ САБАН ТУЕ

(9 июнь, 2019 ел)

Сценарий авторлары – Арча районы Мәдәният йорты методистлары ***Ләйсән Асадуллина*** *һәм* ***Лилия Фәтхетдинова***

(Сабантуй капкасыннан кунакларны кулларына чәк-чәк, ипи тоткан милли киемле кызлар, «колгачылар» каршы ала. Кунакларга колгага бәйләр өчен сөлгеләр бирелә.)

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Гаҗәеп матур авыл иртәсе. Сызылып алсу таң ата. Кошлар сайрый. Таң әтәче кычкыра. Тирә-юньне алтын нурларга төреп кояш чыга. Челтер-челтер чишмә ага. Кызлар чишмәдән йөгерә-йөгерә су ташый. Юл читендәге бәбкә үләннәрендә чык ялтырый. Җырларда җырлана, төшләргә кереп саташтыра торган туган як иртәсе нәкъ шулай башлана.

Аландагы аллы-гөлле чәчәкләрдән нечкә билле умарта кортлары бал җыя. Кошлар сайраган көйгә күбәләкләр очып уйный. Ара-тирә көтүгә чыгучы мал-туар мөгрәгәне ишетелә. Авыл халкы тагын шул бакча, каз-үрдәк, тавык-чебеш арасында кайнаша. Тормыш хезмәттән тора. Ә ул туган туфракка, җиргә барып тоташа. Үстергән. Канат биргән. Тудырган. Яшәткән туган җир! Туган авыл!

2019 ел – Татарстанда Эшче һөнәрләр елы дип игълан ителде. Безнең Арчабыз – авыл хуҗалыгы районы! Ул алдынгы игенчеләре, сыер савучылары белән дан тота. «Хезмәт итсәң илгә, эшең очмас җилгә», дип юкка гына әйтмәгән шул борынгылар! Хезмәт иясе бездә – хөрмәт иясе!

Арча Сабан туе.
2019 елның 9 июне.
Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
рәсми сайтыннан

Киң кырларда иген үстерәләр,
Күп-күп катлы йортлар салалар.
Уңган, тырыш, талантлы да алар,
Барысы да Арчам, синең балалар!

1 нче алып баручы:
Исәнме, җәй, саумы, Сабантуйлар,
Күтеп алган хезмәт бәйрәме.
Туганнарым, якын кардәшләрем,
Бәйрәм итик бергә, әйдәле!

Бәйрәмнәрнең тажы – Сабантуйлар,
Бүләк безгә бөек Ходайдан.
Бу тормышның бөтен матурлыгын,
Хозурлыгын саклый бу мәйдан!

2 нче алып баручы: Хәерле көн, мөхтәрәм милләттәшләр!
Хәерле көн, арчалылар, якташлар, дуслар, туганнар!

1 нче алып баручы:
Сабантуйлар бүген колач җәя,
Татар булган һәрбер төбәктә.
Изге йолаларны саклау кирәк,
Халкым өчен, бүген, бигрәк тә!

2 нче алып баручы: Сабан туе – халкыбызның бик борынгыдан килгән, иң яраткан бәйрәмнәренең берсе. Идел буе Болгарлары һәм Казан арты татарлары һәр елны аны зур эшләр тәмамлаганнан соң бәйрәм иткән. Халык үзе уйлап тапкан әлеге бәйрәм аерым гореф-гадәтләргә таянып үткәрелә, шуларның берсе – бәйрәм флагын күтәрү. Вакыт чоңгылында югалмаган, үзенең тәмен-ямен безнең көннәргә җиткерә алган милли бәйрәмебез Сабантуйны ачык дип игълан итәбез!

1 нче алып баручы:
Борынгыдан килгән гадәт,
Ата-бабай йоласы.
Ипи һәм тоз, баллы чәк-чәк белән
Кунакларны каршы аласы!

Елмаешып каршы чыга кызлар,
Кулларында баллы чәк-чәкләр!
Бәйрәм белән котлап кунакларны,
Елмаюлар бүләк итәләр!

(Чәк-чәкләр тоткан милли киемле кызлар мәйданның төрле якларына таралалар.)

2 нче алып баручы:
Төгәлләнгәч буразнада эшләр,
Салынгач та соңгы бөртекләр –
Татар чыга шулай мәйданнарга,
Күңелләрдә тулы өметләр.

Безнең туган як – борынгы болгар бабаларыбыз гомер иткән тарихи төбәк. Арча районы – татар халкының мәдәниятен, күркәм гореф-гадәтләрен үстерүгә зур өлеш керткән һәм хәзер дә әлеге юлны дәвам итүче, олуг шәхесләр үстерүче бәрәкәтле як. Районыбызда игелекле хезмәтләре белән табыннарны мең төрле сый-нигъмәткә төргән, хезмәт куючы алтын куллы кешеләр яши.

Мәйдан уртасына хезмәтләре белән елдан-ел уңышларга ирешеп, быел исә «Сабан батыры-2019» исеменә лаек булган егетләрне һәм авыл хуҗалыгы тармагын үстерүгә зур өлеш керткән механизаторларыбызны чакырабыз.

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, игенче!
Җаныбызга көч-хәл бирүче!
Шушы бәхет өчен басуда
Таңнан төнгә тирен түгүче!
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, Игенче!

1 нче алып баручы: Мәйданга берсеннән-берсе матур һәм зәвыклырак бизәлгән атлар керә. Җиз кыңгырау чыңнары белән алар күңелләрнең әллә кайсы почмакларын айкап үтәләр. Ел саен матур традициягә кереп, быел да берсеннән-берсе зәвыклырак бизәлгән җигүле атлар арасында бәйге үтәчәк. Иң матур дип табылганы кыйммәтле бүләк белән бүләкләнәчәк.

Каршы алыйк үзләрен.
Эх, күңелле атка утырып
Мәйданнарны бер урау,
Биеп торган ат тоягы –
Иң гаҗәеп кыңгырау!

Эзгә басып, әнә атлар килә,
Беренчесен каршы алыгыз!
Сабан туе гөрләп үтә бездә,
Җырлап, уйнап, биеп калыгыз!

Пар җайдаклар килә мәйдан буйлап:
Батыр егет белән матур кыз.
Бәхет теләп пар догалар чыңлый,
Котлы булсын Сабан туебыз.

2 нче алып баручы:
Сабантуйлар – безнең йөзек кашы.
Кадерләрен белеп яшик лә.
Ярсу юргаларда яшьлек килә,
Юл бирегез, дуслар, яшьлеккә.

Йөзләрендә кояш елмаюы,
Күзләрендә яшен чаткысы.
Алар йөгәнләгән юртакларның
Тоягыннан сибелә йолдыз яктысы!

Сөрән суга яше, карты бүген,
Җигүле ат горур бизәлгән.
Торган җире төзек, мул булсын, ди
Безнең татар шуңа өйрәнгән.

1 нче алып баручы: Сабан туе... Бу сүзне ишетү белән күз алдына чигелгән сөлгеләрне билбау итеп бәйләгән батыр көрәшчеләр, кулларына тальян гармун тоткан егетләр, гөрләп торган кичке уеннар килә. Бүген төсләр, бизәкләр җемелдәвеннән күзләр камаша, милли бизәкләр белән төрелгән мәйдан гына түгел, ачык йөзле, матур киемле кешеләрнең бер-берләре белән дусларча сөйләшүенә кадәр җанга рәхәтлек бирә. Илаһи көчкә ия дә соң безнең Сабантуй бәйрәме!

2 нче алып баручы: Җырлар яңгырап торсын, дуслар күңел ачсын, бәйрәм күңелле узсын. Ирләр, хатын-кызлар арасында ераклыкка сикерү, шахмат ярышлары, таяк тартышу уеннары башланып китте, бүгенге бәйрәмдә көрешеп, бер-берсе белән сынашырга теләгән дусларны, иптәшләрне, танышларны «Аркан тартышырга» чакырабыз. Әйдәгез әле, бәйрәмебез кунаклары, сез дә читтә калмагыз, уеннарыбызга рәхим итегез! Шулай ук теннис уенын да башлап

җибәрдек, ул ирләр арасында һәм хатын-кызлар арасында узачак. Уенчыларга уңышлар теләп калабыз!

1 нче алып баручы: Ә менә авыш колгага һәм туры колгага менү уеннары Сабантуйларның иң борынгыларыннан киләдер, мөгаен. Бүген биредә малайлар да, кызлар да, ирләр дә, хатын-кызлар да үзләрен сынап карый алачак. Иң ныклар өчен көчлеләр сынашуы – авыр таш күтәрү башланып китте. Уңышлар сезгә егетләр!

2 нче алып баручы: Хөрмәтле дуслар, килгән кунаклар! Бүгенге көн – безнеке! Әйдәгез, бергәләп күңел ачыйк, халкыбыз элек-электән яратып уйнаган уеннарда катнашыйк, бәйрәм итик, ял итик! Үзәк мәйданга Сабан туеның традицион уеннарына рәхим итегез. Менә алар: чүлмәк вату, капчык киеп йөгерү, кашыкка йомырка куеп йөгерү, күзләрне бәйләп бүләкләр кисеп алу, сулы чиләк-көянтә белән йөгерү, бүрәнәдә капчык белән «сугышу», күзләрне бәйләп кадак кагу, «торба аша» чыгу, сулы чиләктән алма алу, «чаңгыда йөрү», озын аякта узышу, ласт киеп йөгерү, коймак ашау, әтәч тоту, катыктан акча эзләү һәм башка уеннар. Хөрмәтле бәйрәмебез кунаклары! Уеннарда, алышларда, ярышларда катнашырга чакырабыз. Катнашучыларның, җиңүчеләрнең барысын да бүләкләр көтә.

Гасырларны кичеп, шушы көнгә
Килеп җиткән олы бу бәйрәм.
Һәр ел саен килсен Сабантуйлар
Бирегез сез аңа зур мәйдан!

Борынгыдан килгән милли бәйрәм,
Гөрли, шаулый Сабантуйлары.
Мәйданнарда бил алыша, җиңә,
Татарымның көчле уллары.

1 нче алып баручы: Менә дуслар, күңелләрне рәхәтләндерә, җанга җылылык бирә торган, көтеп алган Сабан туе да ахырына якынлашты. Сабантуй буыннарга куәт, йөрәкләргә дәрт, җаннарыбызга тынычлык иңдерсен! Ил-җиребез имин, бала-чагаларыбыз, туган-тумачаларыбыз сау-сәламәт булсын! Киләсе елга да Сабантуйларында очрашырга язсын! Сау булыгыз!

Күңелләргә рәхәт бирдең, Сабан туе!
Рәхмәт, сиңа, рәхмәт, гүзәл Сабан туе!
Бергә-бергә яшәү язсын гомер буе,
Яшә, туган илем! Яшә, Сабан туе!

ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ САБАНТУЙ ТУРЫНДА ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ:

Вокально-хоровая культура национального праздника Сабантуй: Сборник нотно-музыкальных материалов / Министерство культуры Республики Татарстан, Институт дополнительного профессионального образования (повышения квалификации) специалистов социокультурной сферы и искусства. – Казань: КГУКИ, 2004. – 22 с.

Галеев Э.Х. Татарские народные игры и праздники: книга для учителя. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – 104 с.

Галиева Ф.Г. Современный Сабантуй – наследие Октябрьской революции // Вопросы истории: ежемесячный журнал. – 2019. – № 6. – С. 121-129.

Галимзянов А. И. Игры и праздники тюркских народов: Сабантуй и джиен: народные игры, состязания и развлечения. – Казань, 2013. – 32 с.

Гыйльманов Г. Шагыйрь һәм милли бәйрәмнәр // Түгәрәк уен. – 2020. – № 2. – Б. 39-43.

Җәүһәрева Ф. Сабан туе нинди туй? // Түгәрәк уен. – 2019. – № 2. – Б. 20-26.

Җәүһәрова Ф. Сабан туемы, шау-шулы тамашамы? // Идел. – 2019. – № 5. – Б. 12-17.

Зиатдинов Ф. Ну, вот, жизнь на все про все: фотографии Сабантуя // Казань. – 2010. – № 5. – С. 52-57.

Конно-спортивные игры в соревнования на празднике Сабантуй / Д.Р. Шарафутдинов, Ж.И. Хабибуллин. – Казань, 1979. – 25 с.

Муллануров М. Сабантуй бәйрәмен үткәрү тәртибе: сценарийлар. – Казан, 1997. – 76 б.

Праздники и фольклор татарского народа / Авт.-сост.: А.Ф. Галимуллина, В.П. Хамидуллина. – М.: Содружество культур, 2015. – 79 с.

Сабантуй – праздник труда / Д.Р. Шарафутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 134 с.

Сабантуй: методик ярдәмлек. – Казан: Печат. двор, 2004. – 95 б. – Библиогр.

Сабантуй в фотографиях Рифхата Якупова: фотоальбом. – М., 2014. – 165 с.

Сабантуй. – Казань: Медикосервис, 1999. – 120 с.

Сабантуй: фотоальбом. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 126 с.

Сабантуй-83: Методическое пособие / Д.Р. Шарафутдинов. – Казань: ТГЖИ, 1983. – 144 с.

Семенов Н. Национальные народные праздники в Татарии и их физкультурное значение. – Казань: Татгосиздат, 1945. – 55 с.

Ситдикова А.М. Радуга Сабантуя = Сабантуй балкышы. – Казань, 2013. – 24 с.

Тагиров Э.Р. Сабантуй в локальном и глобальном цивилизационном пространстве: потенциал идей культуры мира в традиционных праздниках народов планеты. – Казань: Центр оператив. печати, 2004. – 48 с.

Татар халык милли бәйрәме – Сабантуй һәм андагы уеннар: Метод. ярдәмлек. – Казан, 1990. – 45 б.

Традиции, рожденные жизнью / Д.Р. Шарафутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1978. – 95 с.

Уразаев Ф.Я. Механизмы сохранения этнокультурной идентичности татарского народа (конец XX – начало XXI вв.). – Казань: Издательство «ЯЗ», 2012. – 227 с.

Уразманова Р.К. Праздничная культура и культура праздников татар: историко-этнографические очерки. – Казань; Набережные Челны: Духовно-деловой центр «Ислам Нуры», 2013. – 189 с.

Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа: историко-этнографическое исследование. – Казань: Татарское книжное издательство, 1984. – 143 с.

Халык уеннары / Д.Р. Шәрәфетдинов, Н.Г. Колчин, А.А. Поцелуев, Ш.Х. Галиев. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1966. – 88 б.

Халык уеннары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 88 б.

Шарафутдинов Д.Р. Ат спорты // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2005. – № 2. – С. 282-287.

Шарафутдинов Д.Р. Атларда чабып кына... // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2006. – № 2. – С. 303-307.

Шарафутдинов Д.Р. Батыры Сабантуя – чемпионы мира // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2007. – № 2. – С. 314-317.

Шарафутдинов Д.Р. Документы миссионерского съезда (Казань, 1910 г.) – важный источник по истории традиционной культуры народов Среднего Поволжья и Приуралья // Отечественные архивы. – 2005. – № 1. – С. 64-70.

Шарафутдинов Д.Р. Древний и вечно юный Сабантуй // Da. Татарстан. – 2005. – С. 50-53.

Шарафутдинов Д.Р. Из истории календарных праздников предков татарского народа // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2005. – № 1. – С. 295-301.

Шарафутдинов Д.Р. Из истории традиционной культуры народов Поволжья: календари и праздники в Волжской Булгарии // Известия Самарского научного центра Российской академии наук. Специальный выпуск. – 2005. – С. 112-119.

Шарафутдинов Д.Р. Исторические корни и развитие традиционной культуры татарского народа. XIX – начало XXI в.: Монография / Д.Р. Шарафутдинов. – Казань: Гасыр, 2004. – 604 с.

Шарафутдинов Д.Р. История становления и развитие народных праздников в Татарстане (XX в.): Автореф. дисс. ... канд. ист. наук. – Казань: Издательство «Гасыр», 1999. – 25 с.

Шарафутдинов Д.Р. История традиционной культуры народов Поволжья в документах Национального архива Республики Татарстан // Вестник Самарского государственного университета. Гуманитарный выпуск. – Самара, 2005. – № 1 (35). – С. 86-97.

Шарафутдинов Д.Р. Национальные виды спорта и игры на традиционных праздниках Сабантуй // Очерки по истории татарской культуры в контексте «Запад-Восток» / Ин-т яз., лит-ры и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. – Казань: Фикер, 2001. – С. 538-551.

Шарафутдинов Д.Р. О происхождении и развитии традиционного праздника татарского народа Сабантуй // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2002. – № 1/2. – С. 227-230.

Шарафутдинов Д.Р. Общеболгарские исторические корни Сабантуя // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2008. – № 1. – С. 297-305.

Шарафутдинов Д.Р. Основные формы календарных праздников: идейно-мировоззренческие и космологические основы; Генезис, исторические корни и этапы эволюции Сабантуя (подход к проблеме) // Сабантуй в локальном и глобальном цивилизационном пространстве (Потенциал идей культуры мира в традиционных праздниках народов планеты) / Шарафутдинов Д.Р., Тагиров Э.Р. – Казань: Изд-во ООО «Центр оперативной печати», 2004. – Разд. 2, 3. – С. 15-47.

Шарафутдинов Д.Р. От Сабантуя к идегейским играм // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 1995. – Май. – С. 239-242.

Шарафутдинов Д.Р. Первый татарский олимпиец // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 1996. – № 1/2. – С. 278.

Шарафутдинов Д.Р. Праздники зимнего солнцестояния и весеннего равноденствия // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2006. – № 2. – С. 296-301.

Шарафутдинов Д.Р. Развитие спортивной культуры на «Сабантуях» в контексте «Запад – Восток» / Д.Р. Шарафутдинов // Очерки по истории татарской культуры (в контексте «Запад – Восток»). – Казань: «Фикер», 2001. – С. 538-551.

Шарафутдинов Д.Р. С майданов Сабантуя – на спортивную арену // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2003. – № 3/4. – С. 290-294.

Шарафутдинов Д.Р. Сабантуй — 2004 // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2005. – № 1. – С. 290-294.

Шарафутдинов Д.Р. Сабантуй / Д.Р. Шарафутдинов // Родина. – 1999. – № 10. – С.102-106.

Шарафутдинов Д.Р. Сабантуй // Da diyalog avrasya. – 2000. – № 2. – С. 114-119.

Шарафутдинов Д.Р. Социалистическая обрядность и воспитание трудящихся // Коммунист Татарии. – Казань, 1984. – № 11. – С. 68-73.

Шарафутдинов Д.Р., Гаффарова Г.В. Письменные источники о космологических воззрениях, верованиях, обычаях и обрядах древних тюрок // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2005. – № 2. – С. 312-319.

Шарафутдинов Д.Р., Горохова Л.В. История традиционной культуры народов Поволжья в документах Национального архива Республики Татарстан // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2006. – № 1. – С. 256-259.

Шәрәфетдинов Д.Р. Җирле һәм глобаль һәм культура пространствосындагы татар бәйрәме Сабантуй // Фәнни Татарстан – 2004. – № 1/2. – Б. 107-110.

Шәрәфетдинов Д.Р. Наил Гәрәев: «Көрәшче осталыгы миңа җиңел генә бирелмәде...» // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 1996. – № 3/4. – С. 200-209.

Шәрәфетдинов Д.Р. Сабан туе – халыкның яшәеше: Фәнни-популяр очерк / Д.Р. Шәрәфетдинов. Сабантуй – образ жизни народа: Научно-популярный очерк / Д.Р. Шарафутдинов. – Казань: Гасыр, 1997. – 310 с.

Шәрәфетдинов Д.Р. Сабан туе – халык яшьлеге // Казан утлары. – Казан, 1978. – № 6. – Б. 126-134.

Шәрәфетдинов Д.Р. Халык бәйрәмнәре тарихыннан / Д.Р. Шарафутдинов // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2003. – № 3/4. – Б. 295-299.

Проект авторлары Алсу Мифтахова,
Гөлназ Латыйпова, Рәмзия Гайфетдинова

Методик кулланманы төзүче Рәзинә Исмәгыйлева
Дизайнер һәм биткә салучы Диләрә Нәүрүзова
Корректор Илнара Гәрәева

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Басарга кул куелды: 20.04.2021
Чыгу көне: 25.04.2021
Заказ: 015781
Тираж: 100 экз.

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78